

АЗАТ ХАТЫН

1926 ЕЛДА ЧЫГА БАШЛАДЫ АПРЕЛЬ • 1978




ЛЕНИН

✻ ЛЕНИН ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА ✻

Хөснул ВӘЛИУЛЛИН музыкасы

УЙГУН сүзләре

Мәйдан уртасына Ильич баскан
алга таба сузып уң кулын.
Һәйкәл түгел, гүя кешелекнең
өмет, бәхет, хаклык символы.

Ул кайчандыр шулай броневикның
түбәсенә менеп баскан да,
кулын изәп хаксызлыкка каршы
көрәшләргә чакыру ташлаган.

Шул уң кулы белән халыкларның
алга барыр юлын сызган ул.
Гади кеше күптән хыялланган
декретларга имза куйган ул.

Көрәшләрдә җиңгән батыр кебек
мәйдан уртасына баскан да,
уңышларга безнең сөенә Ильич,
сөенә тыныч таңнар атканга.

Үзбәкчәдән Шамил **МАННАПОВ**
тәрҗемәсе.







Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!
АЗАТ ХАТЫН 4
АПРЕЛЬ
Иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал. 1978

© «Азат хатын» 1978 ел

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты партия, совет, хуҗалык, профсоюз һәм комсомол оешмаларына, Советлар Союзының барлык хезмәт ияләренә «1978 ел планын үтәү һәм арттырып үтәү өчен социалистик ярыш җәелдерү, җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм эшнең сыйфатын күтәрү өчен көрәшне көчәйтү турында» Хат белән мөрәҗәгать иттеләр. Бу документны бөтен халкыбыз, шул исәптән Татарстан хезмәт ияләре дә, зур рухлану белән каршылады. Республикабыз промышленностеның һәр тармагында, һәр предприятиесендә, колхоз һәм совхозларда Хатта күрсәтелгән бурычларны тормышка ашыру өчен эчке резервларны, мөмкинлекләрне барлау үткәрелде, күтәренке йөкләмәләр кабул ителде. Хәзер исә шул йөкләмәләрне үтәү һәм арттырып үтәү өчен социалистик ярыш көннән-көн киңрәк колач ала бара.

ҺӨНӘР ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Фәүзия НИГЪМӘТУЛЛИНА, токарь, СССР Дәүләт премиясе лауреаты.

Эшкә бирелгәнлек, гомер буе бер һөнәргә тугры булып калу турында фикер йөрткәндә, хәтердә Тукай сүзләре яңара: «...Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә». Аларны мин беренче тапкыр укытучым Рауза Сәйдәшевадан ишеткән идем.

Әле бик яшьли, Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк, токарь станогы артына баскач, бу юлларны бик еш кабатларга туры килде миңа. Станогыма буй җитми, әрҗә өстенә басып, металл кырдырам, үзем, шигырь юлларына өстәп: син бит хәзер һөнәр иясе, тырыш, кызый, тырыш! — дим.

Гаҗәп оста булган икән укытучым! Тукай шигырен өйрәткән булып, безгә алдагы тормышыбызның иң беренче кагыйдәсен төшендергән, сайлаган һөнәрләребезгә мәхәббәт тә уяткан икән ләбаса. Мин металлны яраттым. Минем өчен заводтан да якынрак, станоктан да кадерлерәк нәрсә юк. Классташларым арасында иген игүчеләр дә, төзүчеләр дә, электриклар да, инженерлар да, укытучылар да, врачлар да, очучылар да бар. Алар да тормышларын үз һөнәрләреннән башка күз алларына китермиләр. Бик әйбәт бу, шунсыз бүгенге көн таләпләренә ничек җавап бирер идең!

1978 елда һәр һөнәр иясе алдында гаять зур һәм катлаулы бурычлар куелды. Аларны тормышка ашыру көчләребезне, белемнәребезне, осталыгыбызны бергә туплауны сорый. «Юбилей елы ярышының хезмәт дәртен һәм ритмын сакларга һәм ныгытырга кирәк, — диде иптәш Л. И. Брежнев КПСС Үзәк Комитетының декабрь Пленумында. — Бүген кичәгедән, иртәгә бүгенгедән яхшырак эшләргә. Бүгенге көннең лозунгысы әнә шундый. Ә яхшы дигәнебез — сыйфатка, нәтиҗәлелеккә, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә басым ясау дигән сүз».

Декабрь Пленумында күтәрелгән мәсьәләләргә һәм «1978 ел планын үтәү һәм арттырып үтәү өчен социалистик ярыш җәелдерү, җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм эшнең сыйфатын күтәрү өчен көрәшне көчәйтү турында КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты Хаты»на җавап итеп, республикабыз хезмәт ияләре социалистик ярыш җәелдерделәр, һөнәр ияләренең үзара ярыша-ярыша эшләве — безнең социалистик җәмгыять чынбарлыгында туган иң күркәм һәм бик кирәкле гадәт ул. Ярышта эшчеләрнең осталыгы чарлана, җитезлеге арта. Ярышта кеше үз көченең дөрес бәясен белә, үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен тоя башлый. Ярыш — хезмәтнең нәтиҗәлелеген тәэмин итү чарасы.

Безнең республикада социалистик ярышны әйбәт оештырып, эшләрендә мактаулы дәрәҗәгә ирешкән коллективлар күп. С. П. Горбунов исемендәге авиация берләшмәсе, «Теплоконтроль» коллективы, тегүчеләребез, «Татнефть» предприятиеләре быел да күтәренке йөкләмәләр алганнар. Радио бу предприятиеләрдәге кайбер участокларның, уңган эшчеләрнең инде ярты еллык йөкләмәләрен үтәп чыгулары хәбәр итте.

Ирләр костюмы тегүче Гөлфәния Бәйрәмова, Флүрә Мөхәммәтҗанова унынчы бишьеллыкның инде соңгы елы хисабына эшлиләр. Мондый өлгерлек бары тик үз һөнәрләренең бөтен нечкәлекләрен аңлаган эшче кулыннан гына килә.

Токарь дустым, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Антонина Барышева башлангычы, минемчә, күпләргә үрнәк. Ул үз бригадасы белән 3 еллык планны Конституциянең беръеллыгы көненә, ягъни 7 октябрьгә үтәргә сүз бирде. Тоняның сүзе эштән аерылмый. Чөнки токарьлыкның яңадан-яңа мөмкинлекләрен ача ул. Күрәсең, станогының да яңа мөмкинлекләрен күреп алган. Моңарчы эшләгәнгә караганда яхшырак, нәтиҗәлерәк итеп эшләргә мөмкин бу-

ВӘГЪДӘМНЕ ҮТӘДЕМ

Мин — давыллы еллар комсомолкасы. Беренче бишьеллыклар чорында институт тәмамлап, югары белемле инженер булдым. Шатлыгым эчемә сыймый — илгә аваз саласы; күрегезче, мин гади бер татар кызы, ә үзем дипломлы белгеч, дип кычкырасым килә. Түзмәдем, «Азат хатын» журналына мәкалә язып бастырдым. Мин ул мәкаләмдә Бөек Октябрь революциясенә, халкыма, партиягә олы рәхмәтемне әйттем һәм Ватанымның лаеклы кызы булырга вәгъдә бирдем.

Хәтерлим, минем мәкалә басылган журнал Октябрьның 19 еллыгына багышланган бәйрәм демонстрациясендә таралып бетте.

Бүген вәгъдәмнең үтәлүе турында язарга булдым.

Наркомхозда инженер-конструктор булып эшләгәндә, комсомол оешмасы секретаре буларак, мине Мәскәүгә комсомолның Үзәк Комитетына чакырып алдылар. Безне, комсомолның яшь җитәкчеләрен, беренче секретарь үзе кабул итте. Сорашты. Киңәшләр бирде. Озак кына сөйләшкәч, яңа төзелешләргә өндәп, озатып калды.

Ул елларда мин комиссия составында кинопленка, силикат заводларын кабул итүдә дә катнаштым.

1939 елда, партия һәм хөкүмәтебез чакыруы буенча, комсомол путевкасы белән Ерак Көнчыгышка Комсомольск шәһәрен салырга киттем. Иллешәр градуска җиткән суыкларда шәһәр төзибез. Арылган була. Әмма кичләрен безнең җырлардан, биюләрдән, яңа спектакльләребездән клуб заллары яңгырап тора. Шәһәр газеталарында — безнең рапортлар.

Мине, шәһәр үсә башлагач, төзүче-инженер итеп, заводка күчерделәр. Комсомол комитеты бюросы члены итеп сайладылар. Агитатор да. Завод газетасына мәкаләләр дә язам.

Көтмәгәндә Финляндия безгә каршы сугыш башлады: комсомолның шәһәр комитеты миңа, медсестралар курсы ачып, заводның эшче кызларын укытуны оештыру эшен йөкләде.

Көндезләрен эшлибез, кичләрен укыйбыз, өлкән врачларның практик эшләрендә катнашабыз.

Утыз өч кыз медсестра таныклыгы алганда, сугыш туктады. Әле ул чакта, аларның ул таныклыгының кирәк, бик кирәк буласын беребез дә белми идек.




луын ачыклаган. Яңа башлангычын үтәп чыгуына ул һәрчак шундый ныклы җирлек булдырып тотына. Аңа хәзер йөзләрчә һөнәр ияләре кушылды. Димәк, Барышеваның һөнәренә иҗади, эзләнүчән мөнәсәбәте гомум тырышлыкка юл ярды булып чыга. Шулай ул: эшеңне яратасың икән, аның гел бер дәрәҗәдә генә торуына канәгатьләнә алмыйсың. Эзләнүләр исә һөнәрне тагын да ныграк яратырлык нәтиҗә китереп чыгара.

Безнең буын һөнәр ияләренә бик яшьли эш башларга туры килгән иде. Моның үз уңайлыклары да бар. Шул ук Тукай шигырен дәвам итсәк, мондый юллар укыр идек:

«...Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел».

Яшьли өйрәнгән эш, әлбәттә, күңелгә якын, аңардан син чын ләззәт аласың. Бәхеткә каршы, безгә алмашка килүче яшь буын да осталыкка омтыла. Күптән түгел мин «Спартак» берләшмәсендә табанлыклар әзерләүче комсомолка Рәйханә Әлмиеваның бишьеллык планның дүрт еллыгын комсомолның 60 еллыгы көненә үтәргә вәгъдә биргәнен ишеттем. Өлкән яшьтәгеләргә дә үрнәк булырлык матур башлангыч бу!

Хезмәт, һөнәр кешене яңа җиңүләргә өнди, аны тагын да биегрәк үрләргә чакыра, шулай ук ул синең җилкәгә олы бурычлар да сала.

КамАЗ коллективының үткән елгы социалистик йөкләмәләрен намус белән үтәп чыгуларын беләбез без. Ләкин Татарстанның йөз аклыгы булган бу коллектив үткәндә ирешелгәннәр белән юанып тормады. Быел ул тагын да зуррак йөкләмәләр алды. Яшь кенә коллектив бит үзе. Әмма, аңа карап, республикабыздагы бик күп коллективлар үз мөмкинлекләрен кабат тикшерәләр. Ничек болай! Чөнки КамАЗга үз һөнәренә гашыйк һәм һөнәрен энәсеннән җебенә кадәр белүче уңган яшьләр җыелган.

Үзең яраткан һөнәр шундый нәрсә инде ул, еш кына бөтенләй көтелмәгән адымнарга китерә. Николай Воробьевка әтисе: «Улым, балта остасы булырсың, матур итеп йортлар салырга өйрәнерсең!» — ди-ди үзенең һөнәрен мирас итә. Әмма елга буенда үскән малай уналты яшендә Лаеш балык заводы балыкчылары бригадасына ияреп чыга да, бөтенләй башка һөнәрне ярата. Егерме ел буе балыкчы булып эшли.

Балалары үсә төшкәч, гаиләдә шәһәргә күчү турында сүз куера. Казанга күчәләр. Төзүче булып эшләгәнлектән, шәһәр уртасында квартира ала Воробьев. Кешеләр уңган балта остасыннан канәгать тә булалар. Тик Николай кичләрендә Идел шавын «ишетә», төшләрендә балыклар сикерешүен күрә.

Кабат Идел янына кайта да яр буена ук йорт сала. Хәзер балыкчы Николай Федорович балык заводыннан «балтасы суга төшеп» түгел, авызын җыя алмыйча, якты елмаеп кайта...

Сүз дә юк, һөнәр сайлау нык уйлануны сорый. Яшьли ялгышсаң, хатаны төзәтүе авыр булуы, хәтта соң булуы мөмкин...

Ике ел рәттән кичке санаторийда ял иткән идем. Анда теш врачы булып Әлфия Мөхәммәдиева эшли. Беренче тапкыр дәваланганда аның: «Сызлавы эшегезгә комачауламадымы соң!» — дигәнен мин, бик әйбәт кеше икән бу Әлфия Хәбибовна дип кабул иткән идем. Икенче килүемдә тагын теш дәваладым. Бу юлы да врач: «Бик каты сызлады мы!.. Эшегезгә комачауламадымы соң!» — диде. Мин аның үз эшенең нәтиҗәсе белән генә дә түгел, хәтта үзе дәвалаган кешеләрнең дә хезмәте, ягъни гомуми эш өчен янып-көюен аңладым. Мондый хискә үз һөнәрен яраткан һәм шул ук вакытта һөнәренең кешеләргә мөмкин кадәр күбрәк файда китерүен теләгән кешеләр генә ия. Алар эшкә багышланган вакытның һәр минутын гомуми файдага, ил файдасына багышланырга тиешлеген тирәннән тоеп торалар. Һөнәрең, хезмәтең бары тик вакытның кадерен белгәндә генә сиңа бәхет китерә.

Минут кадере, дип еш сөйләшәбез. Бер минут эчендә дөньяда меңнәрчә яңа приборлар, машиналар, самолетлар, яңа йортлар барлыкка килүен беләбез инде. Әмма моны без сигез сәгатьлек хезмәтебезнең һәр минутында тоеп торабызмы соң!..

Онытабыз шикелле. Бу сүзләрне мин бигрәк тә кайбер ирләр исеменә әйтер идем: унбиш минут эшлиләр дә, «перекур» дигән булып, станок калдырып, биш-ун минут тәмәке тарталар. «Перекурлар» бигрәк тә төзүчеләр арасында еш була. Минутлардан исраф ителгән сәгатьләр җыела, күтәреләсе стена сылыпн бетми кала.

Бүгенге эшеңне иртәгә калдыру, эшеңнән канәгать булмыйча кайтып китү — бу, минемчә, җинаять.

Хезмәтнең олылыгын тоючылар, һөнәреннән тәм табучылар һәр минутның, һәр секундның кадерен беләләр һәм, шуның аркасында, алган йөкләмәләрен вакытыннан элек арттырып үтиләр. Аларны тырышлыкның соңгы нәтиҗәсе, гомуми эш алдына куелган олы максат кызыксындыра.

Кайда тәртип, ныклы дисциплина, кайда эшен яратучы, һөнәр сөючеләр тупланган — шунда хезмәт күтәренкелеге, шунда ярыш ялкыны.

Хезмәт кешесенең, һөнәр иясенең бүген ирешкән уңышлары куандыра да, сокландыра да, уйландыра да...

Унынчы бишьеллыкның быелгы өченче елы да иҗат, хезмәт уңышлары китерсен! Һәр һөнәр иясе, Тукай әйтмешли, «сызганып эшкә бирелгәннән» зур бәхет тапсын иде!

Өлкәннәрдән үрнәк ал!




1941 ел. Мин Казанга әнием янына ялга кайттым. Инде китәм дип торганда гына сугыш башланды. Яңа шәһәрләр, яңа заводлар төзү урынына окоплар казытам, ДЗОТ, ГЗОТлар, блиндажлар эшләтәм.

Фашистны үз оясында тар-мар иткәндә, минем күкрәгемне хезмәт медальләре белән рәттән хәрби медальләр дә каплаган иде инде.

Кабат яраткан хезмәтемә — төзүче инженер эшенә кайттым...

Лаеклы картлык ялына чыкканчы, сөт комбинатында төзү бүлеге начальнигы булып эшләдем. Бишәр катлы йортлар салдык. Балалар бакчасы төзедек. Яңа җиһазлары, 2 мең тонна суыткычы булган сөт заводы салдырдым.

Кичләрен үзем салдырган йортларда утлар күргәч, иртәләрен кибетләргә сөт продукциясе килеп тулгач, көндезләрен балалар бакчасында нәниләр тавышы яңгырап торуын тойгач — сөенеп бетә алмыйм. Димәк, дөрес яшәлгән, җирдә эзем калган. Халкыма, партиягә, «Азат хатын» журналы укучыларына биргән вәгъдәмне үтәгәнмен.

Яшьләр, безнең эстафетаны кабул итеп, КамАЗ, БАМ төзиләр. Әгәр яшь чагым булса, мин дә алар арасында, аларның беренче сафында булыр идем.

Беренче бишьеллык планнарын үтәгәндә Һади Такташның безгә әйткән сүзләрен бүгенге яшьләргә дә әйтәсе килә:

Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үрелә,
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә.


Галия ЕРУСАЛИМОВА,

беренче бишьеллыклар төзелешләрендә катнашкан комсомол ветераны, инженер.

КАЗАН селекционерлары ЭШТӘ

«...Авыл хуҗалыгы культураларының сыйфат ягыннан яңа, тагын да мулрак уңыш бирүчән сортларын камилләштерү буенча селекция эшен яхшыртырга».


(КПССның XXV съезды карарларыннан)



Соңгы елларда һава шартларының көйсез килүе авыл хуҗалыгы фәннитикшеренү институтлары алдына катлаулы бурычлар куйды. Теләсә нинди шартларга яраклаша торган иген культураларының яңа сортларын сайлап алу буенча шактый эшләр башкарылды инде. Казан селекционерлары авыл хезмәтчәннәренә салкынга чыдамлы, тиз өлгерешле ярма һәм кузаклы культураларның яңа сортларын тәкъдим итәләр. Эзләнүләр, сынаулар дәвам итә.

Институтның башка лабораторияләрендә дә җитди эшләр бара. Биология фәннәре кандидаты Равил Бинеев белән өлкән фәнни сотрудник Борис Григорян биохимик анализ үткәрәләр. Селекционерлар һәрчакны аларга таянып эш итәләр.

Өлкән фәнни сотрудник Ләлә Сәгъдиева җитәкчелегендәге тары селекциясе перспективасы күзгә күренеп торган файдалы эшләр белән мәшгуль. Максат — киләчәктә тары уңышын һәр гектарга 55—60 центнерга күтәрү.





Рифкать ЯКУПОВ фотолары.

Бер төркем селекционерлар карабодайның «Сакуровская» дигән яңа сорты өстендә эшлиләр. Галимнәрнең чамалавынча, бу сорт игенчеләргә һәр гектардан 1,5—2 шәр центнер өстәмә уңыш алырга мөмкинлек бирәчәк.

Сез рәсемдә техник Алсу Гафурова, өлкән фәнни сотрудник Фәнүсә Кадыйрова һәм физиолог Вера Галактионова иптәшләрнең теплицада әлеге яңа сорт өстендә контроль тикшерүләр алып баруларын күрәсез.

КЫРЛАРЫМНЫ

Икмәкнең ничек үстерелүен, нинди мәшәкатьләр белән барлыкка килүен, авыл баласы буларак, мин кечкенәдән тоеп, күреп үстем. Шуңадыр, күрәсең, минем бөтен теләгем ата-бабамнан калган шул изге хезмәт белән шөгыльләнү, туган колхозым кырларында тырышып иген үстерү иде. Сигезенче классны тәмамлагач, бераз көч-егәр туплаганчы сыерлар фермасында эшләдем дә, Бөгелмә районының Карабаш поселогындагы профессиональ-техник училищега укырга киттем.

— Гөлсылу,— диделәр миңа Исергәптәге авылдашларым,— механизатор булам, дип җилкенүең вакытлы бер мавыгу түгелме! Тракторга утырырдай егетләр авыл тулы, көлмәсеннәр үзеңнән...

— Анысын киләчәк күрсәтер,— дидем мин аларга.

Сүземдә тордым, укуны тәмамлап, 1971 елны туган колхозым «Урал»га «Киң профильле машинист-механизатор» дигән таныклык тотып кайттым. Әйбәт кенә каршыладылар. Әмма, сизенәм бит, җитәкчеләрдә миңа карата шик-шөбһә бар сыман. Унтугызы тулмаган бу кызыйны башта сынап карыйк диюләредер, гамәлдән чыгып килүче таушалган «ДТ-20» тракторына утырттылар. Күнегү алу өчен монысы да ярап торды.

Беренче мәртәбә әлеге шул «ДТ»га утырган көнемне гомеремә онытасым юк. Кояшлы май ае. Күктә — тургайлар. Ә син тракторыңны гөрләтеп җир йомшартасың. Ә сез беләсезме, парланып торган кара туфрактан нинди хуш ис килә! Яңа гына мичтән чыккан ипи исе! Без училищеда җирне нинди тирәнлектә сөрергә, чи калдырмаска икәнен өйрәнгән идек инде.

Агроном белән киңәшә-киңәшә эшли башлагач, минем өчен әлегә таныш булмаган күп нәрсәләр аңлашыла башлады. Ә бит «агрономия» грек сүзеннән алынган. Агрос — кыр, номо — закон дигән сүз. Димәк, җирне эшкәртү — сөрү, тырмалау, ашлау барысы да билгеле бер закон нигезендә алып барылырга тиеш. Авыл хуҗалыгы производствосында уңышларга ирешү өчен бу законнарны белү агроном, агротехник өчен генә түгел, һәрбер механизатор, игенче өчен мәҗбүри. Кулымда документым бар, һөнәргә ия булдым дип тынычланырга базмадым, кичке мәктәпкә йөреп унберенче классны тәмамладым. Тиешле сынау срогын үтүгә үк үземә «ДТ-25» маркалы өр-яңа трактор тапшырдылар. Күңел тагын да күтәрелеп китте. Планнарымны 120—150 процентка үти башладым. Читтән совхоз-техникумының механика бүлегенә читтән торып укырга кердем. Чөнки, белгәнебезчә, куәтле техника белән коралланган бүгенге колхозларның игенче-механизаторы өчен җирне коры ярату гына җитми, ул уңыш алуның серләрен төшенгән, грамоталы кеше



Ярыш алдынгылары

ЯРАТАМ


булырга тиеш. Без техникумда машина төзелешләрен генә өйрәнмибез, без күпмедер дәрәҗәдә агрономнар да булырга тиешбез. Басуга ашлама чыгарганда мин үземә билгеләнгән җирнең структурасы белән кызыксынам. Җирне бик яхшылап эшкәртергә, яхшылап ашларга, вакытында чәчәргә мөмкин. Әгәр дә инде аңа югары сортлы орлык чәчелми икән, тиешле уңышыңны көтмә, дигән сүз. Мин үзем эшкәрткән җиргә нинди орлык чәчүләре белән дә кызыксынам. Игенче төшенергә тиеш булган мондый мисалларның чиге юк. Басу — спорт мәйданы түгел. Без анда «фәлән вакытта фәлән гектар җир сөрелде яки фәлән гектар ашлык урылды», дигән формаль рекорд кую өчен генә көрәшмибез. Рекорд ул, барыннан да бигрәк, агроном, чәчүче, эшкәртүче, уручы белән бергәләп җыеп алган уңышның нәтиҗәсе, дигән сүз. Югары күрсәткечкә ирешү өчен эшне план нигезендә алып барырга кирәк. Без яз башында ук белгечләр белән бергәләп көчебезне һәм машиналарның эшләү мөмкинлеген тикшерәбез. Бер-береңә ярдәм итешеп, коллектив белән санлашып һәм аңлашып эшләү кирәк.

Былтыр миңа «МТЗ-52» тракторын тапшырдылар. Җитәкчеләребезнең һәм иптәшләрнең тулы ышанычы, тырышлык аркасында мин узган ел яңа уңышларга ирештем. Ягулыкка бермә-бер экономия ясап, планда каралган 800 эталон урынына 1700 эталон гектар җир сөрдем.

Өстәлемдә авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, РСФСРның атказанган агрономы С. М. Скорняковның «Шумерлардан алып безгә чаклы» дигән китабы ята. Анда «үзе ясаган вазага карап сокланган фарфорчы, үзе язган шигыре белән рухланган шагыйрь кебек игенче дә үзе үстергән иркен иген басулары белән горурлана ала», диелгән. Бик дөрес сүзләр бу. Хәзер һәркем — укытучымы, галимме, врачмы, пенсионермы ул — барысын да елның ничек килүе, һава шартлары, чәчүгә хәзерлек, игеннәрнең тишелеше, үсеше, игенченең хезмәте кызыксындыра. Димәк, без — игенчеләр, барыбыз да халкыбызның игътибар үзәгендәге кешеләр.

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Хатына минем җавабым шул: бишьеллыкның өченче елында тагын да тырышыбрак эшләрмен. Тракторым һәрчак төзек булыр. Туган колхозым кырларыннан мул уңыш алу өчен көчемне, тырышлыгымны кызганмыйча, рухланып эшләрмен. Бишьеллыкның өченче елын бик яхшы күрсәткечләр белән тәмамлау — минем намус эшем.

Гөлсылу ХӨСӘЕНОВА,
Татарстан Верховный Советы депутаты,
Баулы районының «Урал» колхозы
тракторчысы.



Маргарита Васильевна Пермьга килде.

КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР

1902 нче елдан бирле революцион хәрәкәттә катнашкан Маргарита Васильевна Фофанованы совет кешеләре яхшы беләләр. Владимир Ильич Ленин соңгы тапкыр подпольеда яшәгәндә нәкъ менә Маргарита Васильевна квартирасында тора һәм шуннан ук «Сез минем баруымны теләмәгән җиргә киттем. Сау булып торыгыз. Ильич» — дигән язу калдырып, кич белән соң гына Смольныйга китә. Ә икенче көнне инде планетабыз кешеләре Россиядә социалистик революция җиңүен ишетәләр. Шул вакыйгаларны искә төшереп, Маргарита Васильевна болай дигән иде: «Константин Петрович булып килде, Ильич булып китте».

Маргарита Васильевна Пермь өлкәсенең Зырянка (хәзер Березники шәһәре) поселогында туган. Шуңа күрә ул, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән, Кама бассейнында агитпароходларның рейс-эстафетасы оештырылгач, өлкән яшьтә булуына карамастан (ул чагында аңа 86 яшь иде), әлеге сәяхәттә катнашырга бик теләп ризалаша. Сәяхәт Усолье пристаненнән, Югары Кама оешмасы коммунистларының 1907 елда В. И. Ленинны партиянең V съездына сайлаган урыннан башланып китте.

Маргарита Васильевнаны алып килгән «Пропагандист» теплоходын Усолье хезмәт ияләре шатланып каршыладылар һәм революционер якташларының чыгышын тирән дулкынлану белән тыңладылар.

— Шундый өлкән яшькә җитүемә карамастан,— диде Маргарита Васильевна,— туган ягыма тагын бер тапкыр кайтырга мөмкинлек туды. Соңгы тапкыр монда кайтуыма инде байтак гомерләр узды. Аннан бирле гаять зур үзгәрешләр булган, Совет властеның әле беренче көннәрендә үк Владимир Ильичның алдан күреп әйткәннәре барысы да тормышка ашкан.

Владимир Ильич Ленин белән очрашу минем өчен гаять зур вакыйга булды. Ул гына да түгел, миңа тормышның иң авыр чорында Владимир Ильичка һәм партиябезгә ярдәм итү бәхете тиде. Мин, партия члены буларак, февраль революциясендә дә, Октябрь революциясендә дә актив катнаштым. Февраль революциясеннән соң мине эшчеләр һәм солдатлар депутатларының Петроград Советына депутат итеп сайладылар. Ул чагында миңа инде 34 яшь иде. Сездә шундый сорау туы мөмкин: «Владимир Ильичның соңгы подпольесы ни өчен соң әле минем өлешкә тигән?»

Эш шунда, Надежда Константиновна чит илдән кайтуы белән үк безнең Выборг ягында эшли башлады. Ул культура-масса эшләрен алып барды. Без аның белән нәкъ менә шул вакытта очраштык һәм дуслаштык.

Озакламый дәһшәтле июль вакыйгалары килеп җитте. Партиябезгә Владимир Ильичның тормышын саклап калу турында уйларга туры килде. Шул чагында Үзәк Комитет членнарына вакытлы хөкүмәт Ленинның иминлеген тәэмин итү турында гарантия бирәме, юкмы икәнен төп-төгәл ачыклау бурычы йөкләнә. Безнең вәкилләребез бернинди гарантия булмавын ачыклагач, Серго Орджоникидзе: «Әгәр сез Ленинның тормышын гарантияли алмыйсыз икән, без сезгә үзебезнең Ильичыбызны бирмибез», дип белдерә.

Моңарчы Владимир Ильич 10 ел буена эмиграциядә яшәгән иде. Һәм менә шул кешегә, Россиядә революция булуга карамастан, тагын подпольега китәргә туры килә. Әйе, Владимир Ильич өчен дә, партиябез өчен дә авыр көннәр иде бу.

Ленин Финляндиягә китәргә мәҗбүр булды. Сентябрь урталарында ул аннан Үзәк Комитетка ике хат җибәрде. Беренчесе аның «Большевиклар властьны үз кулларына алырга тиешләр», дип, икенчесе «Марксизм һәм восстание», дип аталган иде. Юлбашчыбыз үзенең бу хатларында властьны алу өчен бердәнбер юл кораллы восстание икәнен кисәтеп, моны аңлау гына түгел, восстаниене ашыктырырга кирәклеген, югыйсә соң булачагын әйткән иде.

Восстание белән турыдан-туры җитәкчелек итү өчен Владимир Ильич Петроградка кайтырга уйлый. Моның өчен яшерен квартира табарга туры килә. Шул чагында минем кандидатурага тукталалар. Чөнки минем квартира инде моңа кадәр дә партиянең Выборг район комитеты өчен конспиратив квартира хезмәтен үти иде.

Ниһаять, көрәшү вакыты билгеләнде. Надежда Константиновна миңа бары бер генә шарт куйды. Ул да булса — балаларымны кая да булса озату. Чөнки аларның эшкә комачаулаулары мөмкин иде. Мин шулай эшләдем дә. Ике баламны Уфада яшәүче карт әтием белән әнием янына озаттым. Һәм менә 22 нче сентябрь көнне Владимир Ильич үзенең конспиратив квартирасына килде. Ул килешкә инде барысы да әзер иде...

Башта миңа «Константин Петрович» дигән исемне хәтердә калдыруы шактый кыен булды. Чөнки мин Ильичны көткән идем, ә килгән кеше нинди дер Константин Петрович булып чыкты. Яхшылап танышу өчен, Владимир Ильич миңа үзенең пропускын бирде.

Ниһаять, иртәнге ашка утырдык. Үзем һаман уйлыйм: нинди кешене керттеләр соң безгә, ничек яшәрбез, килешеп булырмы? Һәм шунда Ильичка сүз куштым:

— Сезгә минем конспиратив квартирадагы бурычларым турында сөйләргә кирәк иде, — дидем.

— Сезнең иң әһәмиятле һәм иң беренче бурычыгыз, — диде бу, — һәр иртәне чыгып килә торган газеталарның берсен дә калдырмыйча сатып алып кайту. Аннары сорап куйды:

— Ни борчый соң сезне? Выборг ягында бөтен газеталарны да табып булмыймыни?

— Була, — дим, — тик бик кыен.

— Ә нигә кыен?

— Газеталар турында безнең башкарма комитетның күрсәтмәсе бар.

— Нинди күрсәтмә?

— Буржуаз газеталарны сату тыелды.

Бу сүзләр Ильичны бик дулкынландырды. Ул урындыгыннан сикереп торды да аш бүлмәсе буйлап йөренә башлады. Аннары болай диде:

— Ничек инде, шундый күрсәтмәме? Бер нигә дә ярый торган күрсәтмә түгел. Нинди газеталар соң алар безнең өчен. Әлбәттә, дошман газеталары. Ә бит дошманны өйрәнергә кирәк. Ә сез нәрсә тәкъдим итәсез? Шәп эш, әйтәсе дә юк...

Шул чагында мин Владимир Ильичның чын мәгънәсендә журналист булуын, газетаны шашып яратуын, аңа зур игъ-

тибар бирүен, яхшы итеп чыгарылган һәм анык бер максатка хезмәт итүче газетаның кеше кулында нинди көчле корал икәнен аңлавын күрдем.

Газеталарның берәрсен таба алмасам, ул минем теңкәмә тия иде. Ә бит Ильич газеталар ничек чыкканны бик яхшы белә иде. Менә, мәсәлән, «Сәүдә газетасы» турында бер-ике сүз. Исеме үк әйтеп тора, ул политик газета түгел, ә сәүдә газетасы. Ильичка нәкъ менә шул газета кирәк булган. Һәм әйтә бу миңа:

— Әлеге газетаның чыгуы турында мин инде өч игъланны укыдым. Ә сез аны һаман да алып кайтмыйсыз.

Ә мин аңа әйтәм, андый газетаның бөтенләй чыкканы юк, дим.

— Чыкмавы мөмкин түгел, — ди Ильич. — Сәүдәгәрләрнең кем икәнен сез әле белмисез икән. Сәүдәгәр юкка гына акча түздырамыни? Түздырыр сиңа бар. Эзләгез газетаны...

Надежда Константиновна белән без элемтәне ничек тоту турында баштан ук килешеп куйдык. Ул бик гади иде. Лениннан задание алам да, шуның белән партиянең Выборг район комитетына китәм. Ә аны мин бары тик ике генә кешегә тапшырырга хаклы. Кирәкле кешеләрне туры китерә алмаганда, райкомга чаклы булган чакрым ярым араны өчәрдүртәр тапкыр әйләнергә туры килә иде.

Шундый бер вакыйганы хәтерлим. Владимир Ильич газеталардан Вакытлы хөкүмәтнең Җир турында яңа закон әзерләве турында укыган. Законның авторы авыл хуҗалыгы министры уң эсер Маслов була. Ильич миңа шундук: «Известия крестьянских депутатов» дигән газетаның крестьяннар съездына крестьяннар Наказы басылган иске санын табыгыз, дигән күрсәтмә бирде.

Иске газетаны табуы бик кыен иде. Мин аны өчме, дүртме көн үткәч кенә кулга төшердем һәм алып кайтып Ильичка тапшырдым да үзем эшкә киттем.

Эштән кайтып баскычтан күтәрелгәндә кемнеңдер җырлавын ишеттем. Өченче катка менгәч кенә, җырчының Владимир Ильич икәнен сизеп алдым. Менә сиңа Константин Петрович, ни дип аңларга икән соң моны? — дим үз-үземә.

Ишекне акрын гына ачтым да эчкә уздым. Ә ул керә керешемә миңа дәште:

— Нигә шулай озак тордыгыз? Мин инде сезне көтә-көтә арып беттем.

— Берәр хәл булдымы әллә? — дим.

Ильич мине өстәл янына алып килде. Ә өстәл өсте газеталар белән тулган иде. Алар арасында «Известия крестьянских депутатов» та бар. Шуны алып Владимир Ильич 242 крестьян оешмасының съездга булган наказын укый башлады.

— Күрәсезме, — ди Владимир Ильич, — крестьяннар нәрсә таләп итәләр? Җирне бернинди түләүсез тулысынча национализацияләүне таләп итәләр. Ә министр Маслов аларга нәрсә тәкъдим итә?

Мин аны туктаттым да, «Әйдәгез, башта тамак ялгап алыйк», — дидем.

Үзем агроном булганлыктан, бу нәрсәләр миңа беркадәр таныш иде. Шуңа күрә без Владимир Ильич белән аш янында да авыл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләрне тикшердек.

Ашап-эчеп бетергәч, миңа булышып, ашыга-ашыга өстәлне җыештыра башлады. Аннары мине утыртты да әлеге Наказны кычкырып укырга мәҗбүр итте.

— Менә ул ничек, Маргарита Васильевна, — диде укып бетергәч Владимир Ильич, — 242 генә крестьян түгел, ә 242 крестьян оешмасы әзерләгән бит бу Наказны. Күрәсезме, нинди шәп!

Владимир Ильич крестьян мәсьәләсен әнә шулай бик җентекләп, төптән уйлады. Бу мәсьәлә ул чагында безнең партиябезнең төп мәсьәләсе иде. Газеталарны җыеп, үз бүлмәсенә чыкканда, Ильич миңа әйтте:

— Ә сул эсерлар съездда безнең яклы булачаклар, — диде. Әнә нинди зирәк, алдан күрүчән тактик иде Ильич! Владимир Ильичның тактикасын без хәзер дә кулланырга һәм аны бик яхшы аңларга тиешбез...

Маргарита Васильевна агиттеплоход белән Пермь өлкәсендә ике тапкыр булды. Кайда һәм кемнәр белән генә очрашмасын, аны һәр җирдә йотылып тыңлыйлар иде. Һәр килүендә Маргарита Васильевнаны Кама бассейны идарәсе начальнигы урынбасары Хамис Харисович Зарипов каршылады һәм озатып йөрде. Шул чагында алар арасында бик җылы дуслык мөнәсәбәтләре урнашкан иде. Маргарита Васильевна вафат булганчы (1976 ел) хатлар алышып тордылар. Истәлеккә дип бергәләп төшкән рәсемнәре дә бар. Шул рәсемнәрнең берсен мин укучыларга да тәкъдим итәм.

Ягъфәр КАМАЛОВ.

Пермь шәһәре.



КОМИССАР ГАБИШЕВКА БАГЫШЛАП

1918 елның 20 сентябрендә эсерлар һәм инглиз интервентлары 26 Баку комиссарын атып үтерәләр. Бу — гражданнар сугышы тарихының фаҗигале сәхифәсе. Халкыбыз Совет власте өчен корбан булган, Коммунистлар партиясенә тугрылыклы бу кыю улларын беркайчан да онытмый. Азербайҗанда Совет власте урнашкач, 1920 елның сентябрендә революционерларның гәүдәләре Бакуның матур бер мәйданына күчерелә. 1958 елда бу мәйданга һәйкәл куела, 1968 елны шунда Пантеон ачыла.


Бу мәшһүр комиссарларның берсе — безнең якташыбыз Иван Яковлевич Габишев. Ул 1911—1912 елларда Казанның химия комбинатында, механика цехында эшләгән.

Күптән түгел КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында Иван Яковлевич Габишевның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Тантанада И. Я. Габишевның кызы Галина Ивановна Черняева һәм сеңелесе Антонина Яковлевна Нариманбекова да катнаштылар. Татарстан Дәүләт музее каршындагы ветераннар советы һәм М. Вахитов исемендәге химия комбинаты ветераннар советы оештырган бу җыелышта В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты доценты М. Мулюков, химия комбинатының партком секретаре Илгизәр Камалов, комиссарның сеңелесе А. Нариманбекова иптәшләр чыгыш ясады.

Җыелышта Казандагы яңа урамнарның берсенә комиссар Габишев исемен бирү турында Татарстан АССР Министрлар Советы карары белдерелде.

Күренекле революционер эшләгән механика цехы бинасына мемориаль такта куелу уңае белән митинг булды. Һәр сөйләүче ялкынлы комиссарның якты хатирәсен зур дулкынлану белән телгә алды. Аппаратчы Социалистик Хезмәт Герое Галимҗан Сәлимҗанов һәм яшь чагында, Габишев эшләгән цехта ук хезмәт иткән шагыйрь Мөхәммәт Садри чыгышлары аеруча дулкынландыргыч булды. Шагыйрьнең яңа әсәре Иван Яковлевич Габишев истәлегенә багышланган иде. Анда мондый юллар бар:

Бакулылар горурланган егет —
Горурлыгы безнең цехларның.
Йөрәкләргә күчте кайнарлыгы
Прометейлар яккан утларның.



ҺӘР ЕЛНЫҢ АПРЕЛЬ АЕНДА БӨЕК ШАГЫЙРЕБЕЗ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ ҮТКӘРЕЛӘ. КАЗАНДА ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНА ШИГЫРЬ СӨЮЧЕЛӘР ҖЫЕЛА, ШАГЫЙРЬЛӘР АЛАРГА ЯҢА ӘСӘРЛӘРЕН УКЫЙЛАР. КУЛЬТУРА САРАЙЛАРЫНДА, АВЫЛ КЛУБЛАРЫНДА ШАУЛАП ШИГЫРЬ КИЧӘЛӘРЕ УЗА. ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ БУ БИТЕН ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕНӘ БАГЫШЛЫЙБЫЗ.

ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Р. ЯКУПОВ фотолары.

Клара БУЛАТОВА

Кешегә мәдхия

Син, табигать, безсез
телсез, төссез.
Синдә аккан сулар салган эз,
Синдә үскән урман,
төшкән томан
Нигә кирәк булсын Кешесез?

Һич бәхәссез:
синең ташлар ярыр,
Тау актарыр кыргый көчең бар.
Ул көч җиргә бәла булыр иде
Ярый әле шуны җиңә белгән,
Эшкә җигә белгән Кешең бар.

Кыз җыры

Бу дөньяның бер зиннәте —
Аллы-гөлле күлмәгем.
Ул күлмәкнең ни кыйммәте?
Ах, зиннәтнең юк кыйммәте,
Карамаса сөйгәнең...

Таңнар яңа җыр өйрәтте,
Тау чишмәсе көйләрен.
Ул көйләрнең ни хикмәте?
Ах, җырларның юк хикмәте,
Тыңламаса сөйгәнең...

Бер карашы ут дөрләтте.
Тоташ яна йөрәгем.
Бу януның юк хаҗәте,
Ах, януның юк хаҗәте,
Аңламаса сөйгәнең,
Аңламаса сөйгәнең...

●

Син, табигать, гел үк гадел түгел.
Менә шундый гүзәл кешене
Ник урынга ектың?
Бу дөньяны
Шулай янып сөйгән өченме?

Никадәрле анда Җиргә хөрмәт,
Никадәрле яшәү теләге!
Шул хәлдә дә әле кешеләргә
«Ни яхшылык күрсәтергә икән?»
Диеп тибә аның йөрәге.

Үзе белә...
Тиздән хушлашасы...
Бөтенләйгә.
Кире кайтмаска.
Ә шулай да җаны, күңеле якты:
Шәкертләре кала алмашка.

Җирдә шулар бакча яратыр да
Кешеләргә гөлләр таратыр.
Үзе булмаса да,
кешеләрнең
Хәтерләре аны яңартыр.
Хәтерләрдә аның рухы яшәр,
Эше яшәр килер көннәрдә.
...Ә шулай да,
Син, табигать, бер дә гадел түгел
Кешеләргә гомер биргәндә.

●

Бик әйбәт бер яңгыр явып узды,
Керендереп яуды,
мул итеп.
Түбәләрнең тузаннарын юды,
Тәрәзләрне юды йөгертеп.

Җир күпереп, көн чистарып калды,
Чирәмлекләр суга кинәнде.
Киерелеп-тутырып сулыш алды
Коргаксыган талы-тирәге.

Үпкәләргә шифа-озон тулды,
Савыктырып җанны, терелтеп.
Бик әйбәт бер яңгыр явып узды,
Керендереп яуды, мул итеп.

...Җыр өзелеп көйнең яртысыннан
Җан тутыгып-тынып калганда,
Юшкыннарны юып ала торган
Шундый яңгыр кирәк җанга да.

Рәйсә ФӘХРАЗИЕВА

Күңелләр — туган җир көзгесе

Күңелләр — туган җир көзгесе.
Шуңамы, кайларда йөрсәк тә,
Иделнең каенлы ярлары
Җирсетеп-саргайтып йөдәтә...
Күңелләр — туган як көзгесе:
Ал томан... кояшлы яңгырлар.
Туган җир бар чакта дөньяда
Һәр сүзем җыр булып яңгырар!
Күңелләр — табигать көзгесе...
Гүзәллек чагылсын аңарда.
Югалтмыйк туган җир ямьнәрен,
Шуның бит яктысы
җаннарда!

●

Тәңкә-тәңкә карлар төшә...
Кышлар килде быел тагын.
Коелганда тәңкә карлар,
Ник кузгала сагышларым?

Тәңкә карлар төшә чыңлап...
Һай, кышларның тәүге кары!
Кайтыр юлларыма маяк —
Карда каен яктылары...

Ак бөркәнчек япкан дөнья,
Кәләш, гүя, туен көткән...
Киек казлар юлы буйлап,
Минем сагыну явып үткән...

•

Урман өсләп болыт килә,
Күкрәүле дә яшенле...
Яшеннәрдәй ялкын хисне
Җырларыма яшердем.
Офыкларда ни сызыла —
Утлы тасма күкләрдә...
Җырларымның тылсым көчен —
Бирдем язгы күкрәүгә!
Күк күкрәсә ләйсәннәрдә,
Эзләр калса яшеннән.
Минем җыр ул — сиңа кайтып,
Яшеннәрдән дәштергән!

Максуд СӨНДЕКЛЕ

Үткән чордан калган үкенеч

Өсте-башы бөтен — хәзерге
Карчыкларны күрсәм уйланам.
Күз алдыма килә балачак,
Агач башмак кигән үз анам.
Үткән чордан калган үкенеч
Тынгы бирми һаман күңелгә,
Ана күңелен шатландырырга
Кайтып кына китәр идем дә
Сау чагына әни карчыкның
Күпер юк шул җирдә, күктә да,
Поездлар да бармый ул якка,
Самолет та очмый үткәнгә!

Гүя мин бер сабый баламын

Син кайгырсаң мин дә кайгырам.
Син моңайсаң мин дә моңаям.
Гүя мин бер сабый баламын —
Син елмайсаң мин дә елмаям.
Син булмасаң якты дөньяда —
Бу тормышта миңа юк терәк,
Ә син үлсәң, мин дә үләрмен,
Гүя безнең тоташ бер йөрәк!

•

Мәрьям Рахманкуловага
Картлык кагылмый аңа,
Сандугач ул, картайса да,
Сандугач булып кала!

Аермагыз ана сөтеннән

Менә тагы матур яз килде,
Чәчәк атты алма агачы,
Чәчәкләрдән шыткан алмалар —
Алар әле күкрәк баласы.
Комсызланып өзә күрмәгез,
Өлгерсеннәр әле — пешсеннәр,
Яшел көе өзеп алманы,
Аермагыз ана сөтеннән!

•

Балаларын яуда югалткан
Ана рәсмен күрдем төшемдә,
Басып тора карап моң гына
Мәрмәр постаментның өстендә.
Әйтә, имеш: мин саф бакырдан,
Бар кайгымны эчтә тотам мин,
Уф дисәм, бу йөрәк ялкыным
Җирне яндырыр дип куркам мин!

Яз китергән ирләр хакында

(Өч туганым истәлегенә)

Җир өстенә тәүге кар төшкән,
Минем уйлар еллар эзендә,
Кем өстенә яуган бу карлар
Унҗиденче елның көзендә?
Сизгән кебек минем уйларны,
Җир сөйли күк аяк астымда
Каны белән карны эретеп
Яз китергән ирләр хакында!

Рәфикъ ЮНЫСОВ

Бала тапкач

Барын онытып күзәтә ана:
Ишетә аламы?
Күрә аламы?
Матур баламы?

Бар да балада тиешле санда.
Шифалы сөтне чөмерсен өчен,
Башкалар кебек
Йөгерсен өчен, сикерсен өчен
Бар да бар анда.

Шатлык эчертеп күп еллар үтә.
Ә ана һаман тыңлый, күзәтә:
Дөрес күрәме?
Дөрес ишетәме?
Дөрес эшлиме?
Дөрес кешеме?

Үсәсең, кызым...

Үсәсең, кызым, үсәсең!
Быел менә урта группадан
Өлкән группага күчәсең...
Зәңгәр бантик таккан бу чәчеңне
Нинди мода белән кисәрсең?
Нинди һава булыр сулаганың,
Кайда нинди сулар эчәрсең?..


Газеталарда ни бар, илдә-җирдә —
Бөтенесен килә беләсем.
Илне килә тизрәк матурлыйсым,
Җирне килә җылырак итәсем!..
Үсәсең, кызым, үсәсең!

Куркыныч төш

Нинди хәвефкә тап булды икән —
Йоклаган чакта кызым сискәнде.
Джунглида адашканмы ул,
Берәр Бармалей юлын кискәнме?

Янда әнисе өзгәләнә. Их!
Төшенә үзе керер иде ул!
Керер иде дә, бүтән җибәрмәс —
Җитәкләп кенә йөрер иде ул!





Алар тиздән шәһәрнең даны саналган нефть-химия производство берләшмәсенә эшкә китәчәкләр.

Р. ЯКУПОВ фотолары.

Укучылар — нефть-химия берләшмәсе цехларында үз кеше.



Шактый яшь булуына карамастан, Түбән Кама шәһәрендәге 44 нче техник училище турында күп сөйлиләр. Аның даны Татарстанда гына түгел, РСФСР күләмендә билгеле. Уку елының беренче ярты елы нәтиҗәләре буенча училищега РСФСР профессиональ-техник белем бирү идарәсенең күчмә Кызыл байрагы тапшырылды. Укучыларның ГТО комплексын ничек үзләштерүен тикшергәндә, училище Россия федерациясендә икенче урынга чыкты.

Коллектив белән танышсаң, аның кылган эше генә түгел, училище урнашкан бина үзе үк хезмәт өчен җайлы, матур булып күренә башлый. Ә бу уңайлылыкка ирешкәнче күпме көч куелганын уйлап та тормыйбыз.

44 нче училищеда исә эшне нәкъ менә бинаны матурлаудан башлаганнар. Юганнар, чистартканнар, бизәгәннәр. Пөхтәлеккә, зәвыклылыкка омтылу гадәткә кергән. Сүз дә юк, эшкә укытучылар гына түгел, укучылар да тартылган. Хезмәттә дуслык ныгыган. Училище һәркемнең күңеленә иң якын, иң кадерле йортка әйләнгән. Бүлмәләрдә гөлләр үсә башлаган. Сәер-сәер җәнлекләре белән табигать почмагы булдырылган. Мондый урында кешенең үз-үзен тотуы да тәртипкә килә, эленке-салынкылыкка юл калмый.

Менә шул шартларда эшнең иң кыенына, укыту-тәрбия процессын җайга салуга тотыналар.


Училище директоры Василий Иванович Игнатьев сүзләренә караганда, педагоглар коллективы — алга куелган максатка саф күңелдән бирелгән кешеләр. Алар үз эсләренә һөнәр иясе өлгертүне генә түгел, чын кешеләр тәрбияләүне бурыч итеп алганнар. Тәрбия дигәне исә, хисләрне баетуга, тирә-юньдәге матурлыкны күрә белүгә һәм шул хозурлыкны арттыруга юнәлтелгән. Әдәбият, тарих, җәмгыятьне өйрәнү фәннәре әнә шул төп максатка буйсындырылган. Укучылар бу дәресләрдә педагогка күп сораулар бирә алалар, бәхәсләр куера, мөстәкыйль уйлауга юл ачыла, дөнья хәлләренә, төрле күренешләргә карата кешенең үз карашы туа.

Бу җәһәттән әдәбият дәресләрендә ирекле темаларга язылган сочинениеләр игътибарга лаеклы: «Киләчәкне мин ничек күз алдына китерәм», «Бүгенге көн кешесе», «Мәхәббәт», «Тәрбияле кеше», «Гаилә»... Мондый темаларны ачканда, укучының бөтен уй-фикерләре, рухи байлыгы ачыклана. Педагогка исә шул гына кирәк тә. Бөтенләй уйламаганда, укучының гаҗәеп матур сыйфаты күренеп куя яки аңа нindирәк ярдәм кирәклегенә ишарә табыла. Кайбер сочинениеләрдә училище тормышындагы, хәтта аерым педагогларның холкындагы җитешсезлекләр телгә алына. Монысын бөтенләй йөгәннән ычкыну дип тә санарга буладыр, бәлки. Әмма шундый ачыктан-ачык сөйләшүгә юл куймасаң, педагоглар коллективы белән укучылар арасында ихласлыкка ирешү мөмкин түгел.

Беренче курска килгәннәрне иң алдан училище музеена алып керәләр. Һәрберсенең йөзенә: «Бу әйберләрнең барысын да укучылар ясады микәнни?!» — дигән гаҗәпләнү галәмәте чыга. Самолет, паровоз, корабль макетлары, чигешләр, металлга чүкеп ясалган рәсем-



Укучы Резеда Галеева һәр дәрескә шулай җитди әзерләнә.



Тәҗрибәле лаборантка Валентина Попова җитәкчелегендә практика үтү үзе ни тора!



АЛМАШ КИЛӘ

нәр, эш кораллары, мең төрле җайланмалар — барысы да укучылар кулы белән ясалган. Аларның көченә, сәләтенә ышаныч белдерергә генә кирәк.

Училищеның иркен фойесында монда укып чыкканнарның портретлары эленгән: Ленин комсомолы премиясе лауреаты, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, компрессорлы җайланмалар машинисты Даниф Галимәрдәнов, ВЛКСМның XVII съезды делегаты аппаратчы Галиябану Аитова, Җиңү Байрагы янында фоторәсемгә төшү хокукы алган слесарь Фаик Исхаков, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солисты Рафаэль Сәхәбиев...

44 нче училищедан һөнәр алып, Түбән Кама нефть-химия производство берләшмәсенә эшкә килгән яшьләр турында гел мактау сүзе генә ишетәсең. Берләшмәдәге һәр дүртенче кеше исә шушы училищеда белем алган.

Ике оешма арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнашкан. Укучылар берләшмә участокларында, әле училищеда укыган чакта ук, еш булалар. Эш башлаганда инде аларга танышу-күрешүләр өчен вакыт әрәм итәргә туры да килми.

Беренче карашка училищеда һичнинди җитешсезлек юк кебек. Эшләр җайга салынган, укыт та укыт! Әмма директорның канәгать булып утырырга исәбе юк. «Эштә бер генә көн яңалык булмадымы, димәк, коллектив артта калды дигән сүз,— ди ул.— Тормыш бер урында таптанганны кичерми...»

Җитәкченең мондый карашы училищеның киләчәге турында да матур уйларга мөмкинлек бирә. Ләкин туктаусыз эзләнү, тынгысызлык директорның үзенә генә хас сыйфат түгел. Педагоглар һәм мастерлар күбесе алга карап иҗади хезмәт итәләр.

Мастерлар Сәвия Хаҗиморатова белән Галия Сәхәбетдинова монда килгәнче техникум тәмамлаганнар, производствода эшләгәннәр. Әмма училищедагы хезмәткә иҗади мөнәсәбәт аларны үзенә тарткан. Өлкәнрәк педагоглар Галина Трапезникова, Евгения Чекунаева, Леонид Колесников, Нина Каширина алар өчен эшкә бирелгәнлекнең матур үрнәге булып тора.

Училище ел саен илнең төрле предприятиеләренә һөнәр осталары озата. Алмашка төрледән-төрле балалар килә. Педагоглар коллективы алардан данлы эшчеләр сыйныфына лаек шәхесләр тәрбияләүдә зур бәхет таба.

Хәбиб ХӘБИБУЛЛИН.

Мәдинә Фәхретдинова алып бара торган математика дәресләре класстагы барлык укучыларның активлыгы белән үтә.



ЛЕНИН ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА



Maestoso

mf

Мәй-дан ур-та-сы-на Иль-ич бас-

кан ал-га та-ба су-зып уң ку-

лын. Һәй-кәл тү-гел, гу-я ке-

ше-лек-нең ә-мет, бә-хет, хак-лык сим-во-

лы.

1.2.3.

4. Кабатлау өчен

Тәмамлау өчен

нар ат-кан-га, у-кыш-лар-нар ат-кан-


га.

Бу җырның сүзләрен 1 нче биттән карагыз.



КЫЗЛАР ҖЫРЫ





«КЫЗЛАР ҖЫРЫ»

«Гомерләр, йөрәкләр, хыяллар
Мәйданда ут булып калдылар...
Заманны яктырткан шул утка
Чәчәкләр китерә парлылар».

Шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова буыннар эстафетасын менә шул рәвешле тасвирлый.

Әйе, безнең буын кешеләре үткән буынның батырлыгын, фидакарьлеген онытмыйлар, ихтирам итәләр, тормышта, эштә, иҗатта дәвам итәләр. Алар күтәргән байракны күтәреп баралар, алар башлаган җырны дәвам иттерәләр. Ул җырга безнең кызларыбызның да йөрәктән чыккан, изге хисләр белән сугарылган тавышы килеп кушыла.

Әле күптән түгел генә басылып чыккан «Кызлар җыры» исемле китап — моның бер матур мисалы. Бу китапка безнең кызларыбызның соңгы елларда язылган шигъри әсәрләре тупланган. Күбесе укучыларыбызга яхшы таныш, чөнки алар нәкъ безнең журнал аркылы шигъриятькә беренче адымнарын атладылар.

Менә алар, күмәкләп «Кызлар җыры»н җырлаучылар: Роза Хәлиуллина, Илсөяр Ганиева, Флера Гыйззәтуллина, Сәлимә Шәрипова, Венера Туктарова, Лена Шакирҗанова, Нурия Измайлова, Эльмира Шәрифуллина, Нәҗибә Әминова, Энҗе Гыйрфанова, Халисә Мөдәрисова, Заһирә Гомәрова, Фәүзия Кадыйрова, Кәүсәрия Шәфикова, Шәрига Таһирова, Фәйрүзә Мөслимова, Рәйсә Фахразиева, Резеда Вәлиева.

Бу сәләтле кызларның шигъри тавышын бер җыентыкка туплап, китапны төзүче шагыйрь Илдар Юзеев ифрат изге, игелекле эш башкарган.

ГАЛӘМГӘ КАЙНАР СӘЛАМ

Җир орбитасына космик корабльләр җибәрү, космонавтларның, яңадан-яңа мәгълүматлар җыеп, уңышлы очыш ясаулары тормышыбызның аерылгысыз бер өлешенә әйләнеп бара. Юрий Гагаринның галәм киңлегенә беренче башлап юл яруына да инде үткәндәге тарихи вакыйгага мөрәҗәгать иткәндәй карыйбыз. Унбиш-уналты яшьлекләр өчен галәм киңлегенә булган яңа очышлар бөтенләй гаҗәп түгел. Чөнки беренче адым алар туганчы ук ясалган иде инде. Космонавтика шул кадәр тиз «канатланды» ки, хәзер космик киңлеккә чыгып, анда айлар буе хезмәт итү, ягъни төрледән-төрле күзәтүләр алып бару, тикшеренүләр үткәрү илебездәге башка төр эшләр белән бер үк рәткә басты кебек.

Шулай да фәннең бу тармагы, космонавтика үсешенә өлеш кертүчеләрнең һәр адымы безнең уйларны серлелеккә илтеп тоташтыра. Яңа очыш турында хәбәр ишеттеңме, иң элек: «Исән-имин әйләнеп кайта күрсеннәр!» — дип теләп куясың. Космик корабльдәгеләрдән алынган яңа хәбәрләрне көтә башлыйсың. Телевизион тапшырулар вакытында космонавтлар белән уздырылган әңгәмәне йотылып карыйсың. Күзләр экрандагы космонавттан аерылмый: йөзендәге елмаю качмаганмы? Тавышы көрме? Көндәлезләнеп калмаганмы? Ябыгып китмәгәнме? «Тизрәк кайтсыннар иде инде!» — дигән тыелгысыз теләк баш калкыта.

Иң мөһиме шул: очыш саен фән өчен дә, көндәлек тормышыбыз өчен дә гаять әһәмиятле ачышлар саны арта бара. Җир тирәли орбитада соңгы айларда үткәрелгән экспериментлар исә дәвамлылыгы ягыннан да, катлаулылыгы белән дә аеруча бай.

Үткән ел декабренең 10 нчы көне иде. Галәм киңлекләрен тикшерү программасы нигезендә орбитага «Союз-26» космик корабле чыгарылды. Аның белән корабль командиры подполковник Юрий Викторович Романенко һәм борт-инженер Советлар Союзы Герое СССРның очучы-космонавты Георгий Михайлович Гречко составындагы экипаж идарә итте.

Бер тәүлектән соң экипаж әле 29 сентябрьдә үк Җир яны орбитасына чыгарылган «Салют-6» фәнни станциясе белән тоташтырылды. Космонавтлар корабльдән станция эченә күчтеләр һәм күп тармаклы тикшеренүләрен башлап та җибәрделәр. Программага космик киңлектәге физик процессларны, халык хуҗалыгы өчен кирәкле мәгълүматлар алу йөзеннән, җир өслеген һәм атмосферасын тикшерүләр дә, медик-биологик тикшеренүләр дә, техник экспериментлар һәм станциянең борт системаларын, аппаратларын сынау да кергән.

«Салют-26» корабленең очып китүеннән соң нәкъ бер ай вакыт үткән иде инде, орбитада, элек җибәрелгән экипаж белән очрашу өчен, яңа корабль әйләнә башлады. «Союз-27» корабленең командиры — подполковник Владимир Александрович Җанибеков, борт-инженер — Советлар Союзы Герое космонавт Олег Григорьевич Макаров.

Бер тәүлек үтүгә, корабльләр үзара тоташтырылды, космонавтлар барысы бергә «Салют-6» фәнни станциясенә җыелдылар. Дөньяда беренче тапкыр Җир яны орбитасында фәнни-тикшеренү комплексы барлыкка килде. Бу — илебез фәне һәм техникасының яңа җиңүе иде. Совет космонавтикасы үсешенең магистраль юлында алга таба олы бер адым ясалды.

Киң колачлап башланып киткән бу тикшеренүләр әле моның белән генә чикләнмәде. Космонавтлар Җанибеков һәм Макаров «Союз-26» экипажы белән бергә башкарылырга тиешле эшләрен тәмамлагач, космоска очуларына биш көн тулганда, «Союз-26» кораблендә яңадан Җиргә төштеләр. Без аларның исән-сау әйләнеп кайтуларына шатландык. Космонавтларның Мәскәү янындагы «Звездный»га килүен телевизордан күреп тордык, үзләренә тапшырылган бурычны тулысынча башкарулары турындагы рапортны горурлык белән тыңладык.

Әмма эш әле болар белән генә чикләнмәгән булып чыкты. Январьның 22 сендә «Салют-6» станциясе һәм «Союз-27» корабленнән торган фәнни космик комплекска «Прогресс-1» дип исемләнгән автомат рәвештә эшләүче йөк транспорт корабле тоташтырылды. Бусы инде бөтен көткәннәрдән дә узып киткән яңалык иде. Тагын: «Тарихта беренче тапкыр!..» дигән сүзләр яңгырады. Чыннан да шулай. Космонавтика тарихында космик корабльләргә фәнни-тикшеренү станциясенә, өстәмә ярдәм йөзеннән, автоматик эшләүгә көйләнгән йөк корабле җибәрү әлегәчә хыял гына булып кала бирә иде. Ниһаять, мөһим мәсьәләгә чишелеш табылды. «Прогресс-1» кораблендә станциядәге двигательләргә кирәкле өстәмә ягулык, җиһазлар, аппаратура, экипаж тормышы һәм эшчәнлеге өчен зарури булган әйберләр бар иде.

Космонавтикадагы яңалыклар белән танышып баручы һәр кешене «Прогресс-1» йөк корабленең очу һәм «Салют-6» станциясенә тоташу принцибы, әлеге методның киләчәге, ягъни перспективасы кызыксындырды. Газеталарда бу хакта космонавтларның фикерләре басылды. Бусы да бик мөһим — «Прогресс-1» йөк кораблен ясауда инде үзе космик очышта булып кайткан профессор Константин Петрович Феоктистов та катнашкан. Аның сүзләренә караганда, «Прогресс» тибындагы корабльләр станциядәге котылгысыз «чыгымнар»ны каплап бару өчен кирәкле йөкләрне ташый. Билгеле булганча, эш барышында, станциядәге фото һәм кино тасмалары да кими, йөзләгән агрегатларның кайберләре сафтан чыгуы ихтимал, көтелмәгән чатаклыклар да булгалый.

Беренче корабль киткәнгә 83 көн тулганда, «Интеркосмос» хезмәттәшлеге программасы нигезендә СССР очучы космонавты Алексей Губарев һәм ЧССР гражданы тикшерүче-космонавт Владимир Ремек составындагы «Союз-28» корабленең дә шул ук эшкә кушылуы — бу юлдагы әр-яңа баскыч.


Космик комплекс эшчәнлеге — СССР галимнәренең интернациональ дуслыкка таянуларына да бер дәлил. Комплекста Франция галимнәре биргән махсус контейнерда биологик тикшеренүләр алып барылды. ГДРдан җибәрелгән фото, кинотасмалар файдаланылды. Очышның максаты дөнья иминлегенә, барлык кешеләрнең Җирдә матур яшәвенә юнәлдерелгәнгә күрә, комплексның һәр уңышы дөнья тарафыннан хуплана барды.


16 мартта, космоста булуның дәвамлылыгы ягыннан яңа рекорд куеп, Романенко белән Гречко иптәшләр исән-имин килеш Җиргә кайтты. Бу мәшһүр очышта катнашкан батырларны бөтен дөнья кайнар алкышлады.


12 апрельдә билгеләнә торган Космонавтика көненә илебез космонавтикасы эшлекләре әнә шундый зур җиңү белән килделәр.





«АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫНЫҢ 1978 ЕЛГЫ АПРЕЛЬ САНЫНА КУШЫМТА


















ТУЛЫ ГӘҮДӘЛЕЛӘР ӨЧЕН

(54 үлчәм, III буй)
Күлмәкнең ян җөйләре гәүдәне җыйнакландырып күрсәтәчәк.












ЧЫГАРЫЛЫШ

(44 үлчәм, II буй)











җиң





КИЧӘЛӘРЕ ӨЧЕН



Күлмәкне җәйге көнне башка очракта да кияргә мөмкин булачак. Бәби итәкләрне рәсемдә күрсәтелгән үрнәкләр белән чигеп тә чыксаң, күлмәкнең күркәмлеге тагын да артачак.







КЫЗ БАЛАЛАРГА


1. Күлмәк
2. Янтактасыз сарафан


(32 үлчәм)

























15,0
13,0
5,2
9,5
7,4
9,5
11,0
11,0
28,0
28,0
1,0
1,0
6,0
4,0
19,0
жиң


31,0
6,0
яка



20,0
9,6
манжет



1,5
5,5
3
1,2
2
1,5
7
6
2,5
8
7
14,5
8
4,5
6
12,0
59,5
28,5
1
1,5
24,0
арттакта



11
6
10,5
10
6,0
6,0
13,5
13,5
7,5
11
6,5
35,0
61,5
6
2
19
9,5
9,0
алтакта


ЙОН КҮЛМӘК


(48 үлчәм, III буй)

















Туфан МИҢНУЛЛИН

КӘРИМӘ ӘБИ

ХИКӘЯ

Рәуф җил капканы каерып ачып кергәндә, Кәримә әби әрем себерке белән баскыч алдын себереп йөри иде.

— Тумачиәни, нихәл! — дигән тавыш ишетелгәч, карчык сискәнеп куйды, себеркесе кулыннан төшеп китте.

— Абау-җаным, кем ул!

— Мин бу, тумачиәни.

Исен җыеп өлгермәгән Кәримә әби, каткан билен ике кулы белән яза-яза, әкрен генә турайды, тавыш иясенә — җилпүчтәй авызын ерып елмаеп торган Рәуфкә карады, танырга азапланды. Төсмерли алмагач:

— Кем соң син! — дип сорады.

— Әллә танымыйсыңмы! — дип шаркылдап көлеп җибәрде Рәуф. — Тумачиәни дигәч, кем булам соң инде! Рәуф ич мин!

— Рәуф... Рәуф... И, ходаем, синмени!

— Мин, канишны.

Кәримә әби кулларын алъяпкыч итәгенә сыпырып куйды. Селкенми дә ишегалды уртасында басып торган Рәуф янына килде. Рәуфнең сука калагыдай кулын ике учына алып күреште:

— И, ходаем... Менәтерә... Кара син аны... — дип сөйләнде. — Танымый да торам ләбаса... И, ходаем...

— Ә мин сине сразы таныдым. Өегезне дә сразы таптым. Егерме биш ел күрмәгәнгә, барыбер таныдым, онытылмаган. Ә син мине оныткансың, тумачиәни, оныткансың.

— Хәтер иләге тишелгән инде, улым... Күзләр дә әйле-шәйле... Ничек соң болай!

— Сагындым, тумачиәни... Кунакка кайттым. Син әни урынына калган кеше. Үлгәнсеңдер дип уйлаган идем, исән икәнсең әле.

Үлем сүзен ишеткәч, карчык куырылып килде, өнсез калды, керфексез күзләрен чет-чет йомгалап, Рәуфкә карап торды. Аннан соң гына, һушын җыеп, көтелмәгән кунакны өйгә чакырырга керешге:

— Әйдә, өйгә керик... Менәтерә... И-и... Кара син аны... Ни гомер...

Карчык сөйләнә-сөйләнә алдан атлады, тезләренә таянып, баскычтан менде, чоланга, өй эченә үтте. Тумачиәнисенең ун атлаганын ярты атлап, Рәуф карчыкка иярде, ишек өстенә маңгаен бәреп, сүгенеп куйды. Бәләкәй карчыкка таман гына өйнең түшәме дә ике метрлы ир-ат өчен шактый тәбәнәк иде, башын матчага бәрмәс өчен, иелеп түргә узды Рәуф, бүлмәдәге бердәнбер урындыкка утырды. Күптән инде бу галәмәт йөкне күтәреп карамаган урындык ыңгырашып алды да чалшайды. Рәуф өстенә чуар җәймә җәелгән караватка күчте.

Кәримә әби, туктаусыз сөйләнеп, почмак якка теркелдәде. Сырлы-сырлы самоварның ике колагыннан күтәреп, яңадан ишегалдына чыгып китте. Рәуф карават читенә катлап өелгән мендәрләргә ауды. Кон эссе, олы юлдан авылга тикле җәяү кайтып арыган иде ул. Өстәвенә, башының рәте-чираты юк — бәгырьне телеп сызламаса да сулкылдап тора — төзәтелмәгән.

Кәримә әби дигәнебез авылда япа-ялгызы дөнья күреп ятучы сиксән яшьлек карчык иде. Кайчандыр ире, ике малае бар иде аның — сугышка китеп кайтмадылар. Тагын бердәнбер туганы — сеңелесе бар иде — анысы да егерме биш еллар элек дөнья куйды. Туган-тумачадан бүтән һичкеме юк иде. Хәер, сеңелесенең малае бар иде — ул, әнисе үлгәч, йорт-җирен сатып, авылны ташлап китте дә югалды, исәнмедер, юкмыдыр, ишеткән-күргән кеше юк.

Рәуф исән иде. Дөнья гизеп йөрде ул. Әнисенә иркә бала булганлыктан, эшкә өйрәнеп үсмәгәнлектән, бер урында да басылып эшләмәде, бер җирдә дә тупланеп калмады. Ике-өч ай эшләгәндәй итте дә кучеп китте. Гел шулай. Хатыным дип әйтерлек кешесе, тезенә утыртып сөярлек баласы юк. Бәлки, булгандыр, ләкин Рәуф хәтерләми, һәрхәлдә, закон каршында ул буйдак, паспортының хатын, бала-чагаларны теркәп куя торган бите чип-чиста.

Менә шул ике япа-ялгыз кеше — Кәримә әби белән Рәуф бүген очраштылар. Очрашу очраклы иде, әлбәттә. Болганып, уралып йөри торгач, Рәуф туган якларына килеп юлыкты, авылга кереп чыгарга ният итте. Сагынганнан түгел, болай гына, юл уңае туры килгәнгә генә. Үлмәгән булса, әнисенең апасы да бар шикелле анда. Тумачиәнисенең исәнлеген күргәч, Рәуф чыннан да куанды бугай. Ни өчен, нәрсә өчен сөендө, аны ул үзе тоймады, сизмәде. Күңеленең кайсыдыр бер кылы гына зыңгылдап куйды.

Кәримә әби Касыймнарга кергәндә, Касыйм лапас күләгәсендә көрәк сабы таслап маташа иде. Карчык аның янына килде.

— Касыйм күрше, — диде ул, — Әминәнең малае кайтты бит.

Касыйм эшеннән бүленмәде. Күршесенең эче пошканда үзләренә кереп озаклап утыруына, әллә кайчангыларны искә алып, туктаусыз сөйләнүенә күнегеп беткән иде инде ул. Шуңа күрә, карчыкның сүзләре бер колагыннан керә, икенчесеннән чыгып оча. Аның сүзен тыңласаң, көннәр буе эш калдырып утырырга кирәк.

— Әминәнең малае кайтып төште, — дип кабатлады Кәримә карчык.

— Кайсы Әминә! Кайсы малае!

— Менәтерә... Әминәне белмәскә... Күршедә торып...

— Сеңлеңме!

— Сеңлем булмый тагын... Менәтерә... Малае кайтты... Рәуф...

Рәуфне хәтеренә төшерергә тырышкандай, Касыйм, эшеннән туктап, Кәримә әбигә карап торды:

— Ә-ә... Теге ниме!

— Шул инде, шул, Касыйм күрше.

— Нишләп кайткан!

— Кем белә инде, Касыйм күрше.

Касыйм тумранга утырды: кесәсеннән эскәтер чаклы кулъяулык тартып чыгарып, маңгаендагы тирен сөртте.

— Я шуннан...

— Шуннан дип, Касыйм күрше... Кунак бит... Ир-ат... Хәзер ир-атлар... Үзең беләсең... Дөнья күргән... Килешми бит... Коры чәй...

— Өзеп сөйләле, Кәримә апа, вакытым тар.

— Өзеп дип... Беләсең ләбаса... Миңа, карчык кешегә... Кеше алдында... кибеттә... Оят...

— Аракы алып кайтырга дисеңме!

— Шулдыр инде... Ир-атка...

Кәримә әби, яулык читендәге төенне чишеп, акча алды, Касыймга сузды:

— Үзең дә... Кич белән... Берүзенә күңелсез булыр... Сез ир-атлар... Сүзләрегез дә.

Акчаны алмады Касыйм.

— Синең пинсеңне эчәргә кайткан-мыни!.. Тыгып куй акчаңны, — диде.

Кәримә әби үпкәләде. Башка вакытларда ни йомыш белән керсә дә, Касыйм баш тартмый иде, бу юлы, иң кирәкле чакта, гозерен аяк астына салырга җыена. Җитмәсә, мәрхүмә сеңелесенең малаена тел тидерә. Эчәргә кайткан, имеш. Нишләп эчәргә кайтсын! Сагынып кайттым диде, ләбаса. Ялгыз дигәч тә, әллә Кәримә бүтәннәрдән кимме! Кунакны әллә кунак итә белмиме! Хәзерге ир-атның коры чәйгә генә риза булмавын әллә ул белмиме! Касыйм үзе бит, үзләренә ир-ат затыннан кунак-мазар килсә, өстәл уртасына шул нәмәстәне утыртып куя.

— Тыгып куй акчаңны, — дип кабатлады Касыйм, — кич белән керермен.

— Керермен дисең дә...

— Булыр кирәкле нәрсә...

— Булыр дисең дә...

— Әйттем бит инде...

Касыйм, кеше белән сөйләшкәндә, һәрчак шулай кырысрак сөйләшә иде. Каршы дәшкәнне яратмый. Гадәте шундый. Ләкин эчендә этлеге юк. Әйткән сүзендә, вәгъдәсендә тора, бик ярдәмчел. Әмма бу юлы бүтән нәрсә бит, акчага бәйләнгән. Ничек инде Кәримә үз кунагын кеше акчасы белән сыйласын...

Урамга чыккач, Кәримә әби капка төбендә уйланып озак басып торды. Барыргамы кибеткә, юкмы! Барсаң, кеше алдында оят, өстәвенә Касыйм ачуланыр, сүзен тыңламаганны өнәми, бүтән йомыш белән керсәң, кире борып чыгарырга да күп сорамас. Бармасаң... Каян килгән ул затсыз нәмәстә, шул булмаса, өстәл янындагы ир-атның йөзе кара коела бит, ашаган ашы аш түгел, эчкән чәе чәй түгел. Үзе күптән инде кунак сыйламаса да, ишетеп белә Кәримә әби — хатыннар шулай дип зарланалар. Зарлансалар да...

Үз ишегалдына үтте Кәримә әби. Йа алла, самавары кабызылмаган икән. Күмере кайда соң әле! Өйдә, мич алдында бугай.

Кәримә әби өйгә кергәндә, караватны иңләп-буйлап яткан Рәүф гырлап йоклый иде.

Кич белән тавыгын суйдырып аш өлгертте Кәримә әби, бишенче тапкыр самаварын яңартты. Ниһаять, Рәүф тә уянды, аның уянганын сизгәндәй, Касыйм да кереп җитте.

— Нихәл, — дип кул биреп күреште Касыйм.

Рәүф Касыймны таныды, тик исемен генә искә төшерә алмады.

— Касыйм абзыең булам мин.

— Беләм, — дип алдашты Рәүф.

— Кайттым диген!

— Кайттым, Касыйм абзый. Тумачиәни — әни урынына калган кеше.

— Шулайдыр, — диде Касыйм, үзе, каш астыннан гына сөзеп карап, Рәүфнең өс-башын тикшереп чыкты. Әлләни түгел — якасы беләүләнеп беткән күлмәк, үтүк күрмәгән чалбар, шомарган-ялтыраган, җиң очлары сизрәгән пинҗәк.

— Кайларда инде! Семьяң-фәләнең бармы!

Мондый сорауны көтмәгән Рәүф каушабрак калды. Аннан рәхәтләнеп ялганларга тотынды. Зур гына бер шәһәрдә яши икән ул, зур заводта мастер булып

Надыйр АЛЬМЕЕВ рәсеме.



эшли икән, акчаны күрәп ала, оч булмәле фатиры, хатыны, ике малае, ике кызы бар.

Кибәкне бөртектән аера белгән, хәтта дөрес сүзгә дә шикләнебрәк карый торган Касыйм Рәуфнең сөйләвенә ышанмады, әлбәттә:

— Шулайдыр, шулайдыр, — дип, мыек астыннан елмаеп кына утырды.

Ул арада Кәримә әби өстәлгә аш куйды.

— Яле, тумачиәниеңнең ашыннан авыз итик әле, — дип, Касыйм кулына кашык алды.

Рәуф кашыкка тотынырга ашыкмады, өстәл өстенә иң кирәкле нәрсәнең утыртылуын көтте. Көткән нәрсә күренмәгәч, түзмәде:

— Тумачиәни, алып куйган берәр нәрсәң юкмы шунда! — дип сорады.

— Ни нәрсә ул, улым! — диде Кәримә әби.

Карчык төшенмәгәнне Касыйм бик тиз аңлады.

— Ачуланма инде, туган, без Тумачиәниең белән эчүне ташлаган идек шул, — диде.

Рәуфнең ни сораганын шунда гына төшенде Кәримә әби. Аракы турында онытып өлгергән иде инде ул. Оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булды. Менә бит... Әйтте бит ул... Ышандырды бит Касыйм күршесе... Әй, бу кеше дигәнең... Юк инде, юк, конең кешегә калгач... Үзе барган булса кибеткә... Касыймга ни, үз кунагы булмагач, гаменда дә юк. Һичнн белмәгәндәй утыра. Адәм көлкесенә калдырды ләбаса... Ни дип әйтә әле җитмәсә.

— Утыр, Кәримә апа, — ди. — әнисе урынына калган кеше алдында эчү кунакка да килешми, — ди, — иң яхшысы — чәй анын, Рәуф алып кайткан күчтәнәч канфитлар белән чәй эчәрбез, — ди.

Шулай диде Касыйм. Утыз елга якын күзгә-башка күренмәгән, әнисе урынына калган кешегә бер кәлимә сүз язып хат җибәрмәгән, авылда чагында да кешене кеше, туганны туган дип белмәгән Рәуфнең кинәттән генә кайтып төшүенә сәерсенгән иде ул. Һәм сизенүе дөрес булуына инангач, ачуы чыкты. Эт итеп сүгәргә җыенган иде, барыбер файдасы тимәячәген аңлады, төртмә сүзләр белән кунакны мыскыллап утырды. Кәримә әби шикәре белән чәй эчкәч, карчыкка рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Касыймның төртмә сүзләренә исе китмәде Рәуфнең, аларны ишетмәде дә диярлек. Уе башкада иде аның: әллә ничә елга бер кунакка кайткан. Шунда да аш кына ашатып, чәй генә эчертәләр.

Кәримә әбинең дә үз хәсрәте — бердәнбер туганы әллә ничә елга бер кунакка кайткан, шунда да бүтән кешеләр сыман кунак итә алмады, оятка калды. Әллә ничек кенә булды.

Өстәл артында озак кына сүзсез утырганнан соң Рәуф:

— Кая, тумачиәни, биш сум биреп тор әле. Минем акча чумаданда калган, чумадан камера хранениедә, иртәгә алып кайтып бирермен, — диде.

Кәримә әби, кабалана-кабалана, яулык читен чиште, уилык алып, Рәуфкә тоттырды. «Камера хранение»нең ни икәнен дә, ни өчен чемоданның анда калуын да сорашып тормады.

Рәуф акчаны йомарлап кесәсенә тыкты да:

— Мин хәзер кайтам, тумачиәни, — дип чыгып китте.

Рәуф ярты төн узгач кына исереп кайтып керде. Кәримә әби аны көтеп баскыч төбендә утыра иде. Кунакның кәефе шәп иде. Карчык янына утырды да көлеп җибәрде:

— Нихәлләрдә яшисең соң, тумачиәни!

Туганының хәл сорашуына куанып бетә алмады карчык:

— Аллага шөкер, улым. Менә исәнсау...

— Башта мине танымадың, ә, тумачиәни. Картайгансың.

— Үткән гомер үтә инде, улым. Синда байтактыр инде.

— Кырык җиде, тумачиәни... Шушында яшәп ятам диген, ә!

— Аллага шөкер.

— Син миңа ачуланма, ярыймы.

— Ниткән сүз ди ул ачулану. Рәхмәт искә алып кайтуыңа.

— Син курыкма, тумачиәни. Түлим мин сиңа ул акчаңны. Йөзе белән кайтарып бирәм. Акча бар ул бездә. Курыкма син. Ничек соң, тумачиәни, сине монда рәнҗетмиләрме! Обижать итсәләр, миңа әйт, мин сөйләшә белермен. Синең ирең, малайларың сугышта үлгән, сине рәнҗетергә берәүнең дә хакы юк.

— Юк, юк, ниткән рәнҗетү... Аллага шөкер. Йорт-җиремне карап тора колхоз, ашарыма биреп тора... Тел тидергән кеше юк. Мәктәп малайлары утынымны кисеп бирәләр, суын китерәләр.

— Шулай тиеш. Курыкма, тумачиәни, мин барында курыкма. Яшәтәм мин сине. Шуның өчен кайттым мин. Юк, үзем белән алып китәм. Китәсең килмәсә, менә диген өй салып бирәм. Бу өең тузган. Урыс капкалы йорт салып бирәм. Бу җил капкаңны... — Рәуф урыныннан торып капка янына барды. — Бу капканы, тумачиәни...

Рәуф, чайкалып китеп, капкага таянды, капка белән бергә авып төште. Торып, ишегалды буйлап йөренде. Туктаусыз сөйләнде. Әллә ниләр вәгъдә итте. Кәримә әбине кочаклап көлде, җылады. Әллә кемнәргә йодрыгы белән янады. Аннары, өйгә үрмәләп кереп, идәнгә сузылып ятты. Кәримә әби:

— Караватка ят, улым, — дип әйтеп караган иде, Рәуф ямьсез итеп карчык аңламаган телдә сүгенде дә гырлап йокыга китте.

Кәримә әби ишегалдына чыкты, капка янына килде, капканы күтәреп куярга теләп иелде. Башы әйләнеп китеп, җиргә утырды. Озак утырды ул. Уйланып утырды. Мең төрле буталчык уй арасында иң татлысы да бар иде. Туганы табылды бит, җир йөзендәге бердәнбер туганы табылды. Сеңелесенең малае... Кайткан — онытмаган... Сагынып кайткан...

Нәниләргә укыгыз

Нур ГАЙСИН

Үс тә үс...

Җәйге кояшлы көндә
Күктә кар тавы йөзә,
Бит пешәрлек эсседә
Ничек эреми түзә.

Әни әйтә: — Кар түгел,
Бу, ди, йөзә ак болыт,
Яшәртергә игенне
Явар, ди, яңгыр булып.

Болытка күзне текәп:
— Алайса — дим әнигә, —
Кар шикелле ак булгач,
Кар булып яумый нигә?

— Күп нәрсәне белергә
Син әле, — ди, — кечкенә.
Мәктәптә өйрәнерсең,
Таза булып үс кенә.

Энемнән дә олы мин,
Әтинең зур улы мин!
Сәер безнең әниләр,
Һаман: «Үс тә үс!» — диләр.

Үпкәләш

Җир белән җил үпкәләште;
Кара син шаян җилне,
Басудан карны себереп,
Шәрә калдыра җирне.

Болытларны куганга да
Җир үпкәләгән җилгә,
Күк гөмбәзе аяз булгач,
Яңгырлар төшми җиргә.

Юлларын буып тау-җирләр
Җибәрми тота җилне.
— Нигә юлны кисәсең! — дип,
Җил дә орыша җирне.

Мин телим тату яшәвен
Җир белән шаян җилнең,
Җил яңгыр-карлар китерә,
Җир — бәрәкәте илнең.

Озын тел

Мине, озын телле, диеп
Әйтәләрдер, белмим, нигә,
— Телең озын! — дип битәрли,
Бер сүз әйтсәм әнием дә.

Күзгедән дә карап алам
Күнемә мин әллә ничә,
Әни уйнап әйтәдер ул,
Телем һаман элеккечә.

Телем озын түгеллеген
Белмәскә мин баламыни,
Озын телле булган кеше
Матур сөйли аламыни?

Шигырь сөйләгәндә апам:
— Әйбәт! — диеп куймас иде,
Әгәр дә тел озын булса,
Авызыма сыймас иде.

Сөйләшкәндә иреннәрне
Ачып-яба алмас идем,
Табында да, аш тутырып,
Кашык каба алмас идем.

Нигә, озын телле, диләр,
Менә шуңа җавап тапмыйм,
Тик шаяртып әйтәдер, дип,
Әнигә дә гаеп такмыйм.

МЕНӘ СИН ДӘ ҖИТКӘН КЫЗ БУЛДЫҢ...

Кеше гомерендә шундый бер чак була: сизми дә каласың, дөнья кинәт үзгәрә дә куя. Кичке шәфәкъ ай-һай кызыл, ай нурлары бигрәк якты, иртәнге җил битне бигрәк назлы итеп сыйпый, чәчәк таҗларына кунып, кояш нурларында җемелдәгән чык тамчылары күзне бигрәк нык чагылдыра... Һәркайда әйтеп бетергесез гүзәллек, күңелне әле якты моң, әле тыелгысыз дәрт белән тутыра торган серлелек. Шул серлелек йөрәкне ашкындыра, офыкның аръягына барасы, йолдызларга менәсе, дөньяның бар серләрен ачасы килә, җырлыйсы, биисе, моңарчы беркем кулыннан килмәгәнне эшлисе килә. Нишләгән бу дөнья?

Юк, дөнья үзгәрүдә түгел хикмәт, синең гөл чәчәкләрен дә, ай нурын да, кояш баешын да күп тапкырлар күргәнең бар иде бит, тик син аларны бик гади нәрсәләр дип кабул итә идең, аларның гүзәллеген дә, серлелеген дә сизми идең.

Син үзең үзгәрдең, күзләрең, колакларың сизгерләнде, күңел күзең ачылды.

Табигатькә генә түгел, җырга-моңга, китапларга, рәсемнәргә дә мөнәсәбәтең үзгәрде синең. Элек бер дә исең китмәгән моңнар күңелеңне кузгата, күп тапкырлар күргән рәсем каршында беренче күргәндәй сокланып, аерыла алмый басып торасың, киләчәктә үзеңне зур ачышлар ясаучы яисә гүзәл сәнгать әсәрләре иҗат итүче, яки зур батырлыклар кылучы дип күз алдына китерәсең. Матур ул киләчәк һәм синең аны тизрәк якынайтасың килә. Һәм син ул киләчәктә ялгыз түгел, анда синең белән янәшә әлегә билгесез кемдер бар. Кем ул? Синең аны тизрәк төсмерлисең килә, алай гына да түгел, тизрәк очратасың, күрәсең килә. Син китапларның элек бер дә кызыксыз тоелган битләрен — мәхәббәткә багышланган бүлекләрен кат-кат йотылып укыйсың. Башкаларга сиздермәскә тырышсаң да, егетләр белән кызлар арасындагы мөнәсәбәткә кагылышлы һәр сүзне кызыксынып тыңлыйсың. Анда да сер, дулкынландыргыч, кайчандыр ачылачак, ләкин бүген үк күңелне ашкындыра торган зур сер ята. Яшерен - батырын түгел, синең ул серне дә тизрәк ачасың килә.

Яшьлекнең башлангыч чорында һәркем кичерә торган ашкынулы хисләр бу. Әгәр синең күңелдә алар кузгалган икән, димәк, син гомереңнең бик мөһим, җаваплы, катлаулы чорын кичерәсең, дигән сүз.

Син аның катлаулылыгын үзең дә сизеп яшисең. Гүзәллекне күрү, нәрсәгәдер омтылу белән бергә, еш кына һичбер сәбәпсезгә күңелең төшенке була, кайчак үзең дә теләмәстән әниеңә яки башка берәр якын кешеңә тупас сүз әйтеп ташлыйсың, соңыннан үкенәсең, ләкин ниндидер кирелек гафу үтенергә ирек бирми. Кайвакыт тик торганда күңелең тула.

Шуның өстенә күп кенә кызлар үз кыяфәтләреннән үзләре оялалар, кулларын кая куярга белми аптырыйлар. Кайсылары көзгегә карагач, бөтенләй кәефсезләнәләр: аларга борыннары ямьсез кебек тоела яки битләренә бетчә чыгып теңкәләренә тия. Ләкин көзгегә карамый да түзеп булмый — һаман үзеңнең нинди икәнеңне беләсе килә, чибәр буласы килә, бизәнәсе килә!

Болар барысы да балалыктан яшьлеккә күчү чорына хас, табигый сыйфатлар. Организмда һәм психикада булган бу үзгәрешләр беренче чиратта нерв системасының һәм эчке секреция бизләренең эшчәнлегенә бәйле. Бу чорда җенси бизләрнең эшчәнлеге аеруча активлаша, шуның нәтиҗәсендә кыз баланың гәүдәсе формалаша, күкрәкләре калкулана, оча сөякләре киңәя, тире астына май катламы үсеп, буй-сыны нәфисләнә. Аның тавыш яңгырашы да үзгәрә, холкы-фигыле дә бөтенләй икенчеләнә. Еш кына бик тере, тынгысыз бала, өлгергәч, тыйнак, тыныч кызга әверелә, ә бик тыныч тоелган бала еш кына шат күңелле, хәрәкәтчән кыз булып җитешә.

Бу үзгәрешләр берничә ел буе дәвам итә һәм организм өчен җиңел генә бирелми, билгеле. Бер талпыну, бер боегу, сәбәпсезгә күңел тулу, тынгысызлык шуның белән аңлатыла да. Ләкин моңа борчылырга ярамый, яшьлекнең иң матур еллары алда әле. Кайчан бер көн, ана кызына сокланып карар да:

— Менә син дә җиткән кыз булдың! — диярк.

Тик бу сүзләрне ишеткәндә кыз бала үзенең тышкы кыяфәте, буй-сынының нәфислеге белән генә мактанырлык булып калмасын иде. Аның акылы да җитлеккән, олы тормышка аяк басар өчен белеме дә җитәрлек булсын иде.

Җитлегү чоры кешенең физик үсешендә генә түгел, акыл үсешендә дә бик зур роль уйный. Үсмер чакта кеше бик күп нәрсә белән кызыксына, аеруча зиһенле, зирәк була, аның акылы бик күп мәгълүматны үзләштерә ала. Бу чорда укылган, өйрәнгән нәрсәләр хәтергә нык сеңеп калалар һәм гомер буе онытылмыйлар.

Әдәбият-сәнгатьтән яшь чакта алган тәэсирләр асылда кешенең зәвыгын формалаштыралар.

Бу чорда кеше үзенә һөнәр сайлый, аның акылы утыра, холкы-фигыле, дөньяга карашы формалаша. Бу нәрсәләр нигездә аның киләчәк язмышын хәл итәләр.

Җитлегү чорында яшьләр спорт белән мавыгалар һәм кайберәүләр, рекордлар куеп, чемпионнар булалар.

Кыскасы, өлгереш чорында кешене кызыксындырган һәм аның өчен мөһим булган мәсьәләләр тормышның үзе шикелле үк күп төрле һәм катлаулы. Гаилә тормышына әзерлек, үзеңә тиң яр сайлау — шушы җитди мәсьәләләрнең берсе.

Бәхетле гаилә кору өчен иң элек ярата белергә кирәк.

Ә син ярата беләсеңме?

Күпләр бу сорауга гаҗәпләнәләр. «Ничек инде ярата белмәскә? Эчендә җаны булган һәркем ярата белә!» — диярләр алар. Ләкин, чынлабрак уйлап карыйк әле: һәркем дә ярата белә микән соң? Әллә кайберәүләр яратсалар да үзләрен генә ярата беләләрме? Бар бит андыйлар, егетләр арасында да, кызлар арасында да очрап тора.

Бездә яшьләргә үсәргә, ныгырга, яшь гомерләрен матур үткәрергә тулы шартлар тудыру турында күп сөйләнә, алар турында кайгыртучанлык күрсәтелә. Өлкәннәр аларның көйсезлеген дә, холыксызлыгын да акларга омтылалар: күчеш чоры, авыр чор, янәсе. Ләкин бер нәрсәне онытып җибәрәләр: кеше гомерендә авыр чор бер үсмер вакыт кына түгел, кыен вакытлар булыр, җайсызлык килгән саен көйсезләнергә гадәтләнсә, аны кем генә көйләп бетерә алыр икән?

Кайбер яшь кызларның тышкы кыяфәтеннән, кием-салымыннан ук үзләрен дөньяның кендеге дип хис итүе күренеп тора. Кыйммәтле мех бүрекләр, яхшы туннар, чит илдә тегелгән итекләр кигәннәр. Ә әниләренең өстендә җиң очлары тузып беткән иске пальто. Андыйлар турында: «Кызы бистә бикәсе, әнисе киндер көлтәсе», — ди халык. Гаилә тормышында да иң беренче чиратта үзе өчен кирәкне генә кайгыртырга гадәтләнмәсләр микән андый кызлар? Бик ихтимал. Ата-анасының хәленә керә белмәгән кеше, ай-һай, иренең хәленә керә алыр микән... Анасын кызгана белмәгән кеше баласына игътибарлы, кайгыртучан, сабыр мөнәсәбәттә була белер микән?

Җырларда макталган, китапларда тасвирланган гүзәл мәхәббәт хисе үзе турында гына кайгыртырга күнеккән буш күңелләрдә үсеп чыга алмый. Әгәр дә бала үскәндә үзенең ата-анасын, абый-энеләрен яки апа-сеңелләрен, үзе укый торган мәктәпне, үз Ватанын яратырга өйрәнмәсә, аның характерында тупас эгоизмның башлангыч сыйфатлары тәрбияләнсә, аның үзе сайлап алган ирен яки хатынын чын-чынлап ярата алуы бик шикле.

Яшь чакта кеше турында кайгыртырга өйрәнү бик мөһим. Башкалар турында кайгырта белмәгән кеше мөгаен ярата да белмәстер, матур гаилә дә кора алмастыр. Гаилә тормышында ир кешегә дә, хатын-кызга да еш кына

сөйгәне хакына янсә балалары хакына үз рәхәтеннән ваз кичәргә, алар өчен зур мәшәкатьләр күрергә туры килә. Бу табигый, шунсыз семьяны алып бару да, балаларны яхшы тәрбияләү дә мөмкин түгел. Моңа да яшьтән өйрәнеп үсәргә кирәк. Уналтыда-унҗидедә өйрәнмәсәң, «картаеп каткач буыннар» соң булмас микән?

Яшерен-батырын түгел, күп кенә яшьләр тормыштан гел үзләренә уңайлылык кына таләп итәргә күнегеп үсәләр. Ата-анасыннан мең гаеп табып, аларга үпкәләп йөрүчеләр дә шактый. Кайбер кызлар: «Минем әни мине тирги, кич белән йөрергә чыгармый, мәктәптән кайтуыма ашарга пешереп куймый», — дип зарланып редакцияләргә хат та язып җибәрәләр.

Әнисенең хәленә керү, аның мәшәкатен җиңеләйтергә тырышу турында уйлап та карау юк.

Кеше күңелен, кичерешләрен аңлый белү, аның хәленә керә белү, аның хаталарын гафу итә белү дә гаилә тормышында бик кирәкле сыйфатлар. Моңа яшьтән өйрәнергә кирәк. Югыйсә кайбер яшьләр кешенең гаебен тиз күрәләр, үзләрен беркайчан да гаепле санарга теләмиләр, шуның аркасында гашыйклар арасында күп аңлашмаучылыклар, гаиләдә күп низаглар килеп чыга.

Үз-үзләрен көйләргә генә күнеккән яшьләр еш кына килешмәгән якларын ата-аналарыннан күрәләр, «алар безне дөрес тәрбияләмәгәннәр», дип өлкәннәрне гаеплиләр. Әмма дөньяда үз-үзеңне тәрбияләү дигән нәрсә дә бар бит әле. 12—15 яшьтәге кеше инде өлкәннәр авызына гына карап тормый, китаплардан, кинофильмнардан, телевидение тапшыруларыннан да, тирәягындагы тормышны күзәтеп тә бик күп мәгълүмат ала, акны карадан, яхшыны яманнан аера белә, һәм, шул позициядән чыгып үзенең тормышына, гадәтенә, холкына тәнкыйть күзе белән карый ала. Әгәр үзендә начар гадәтләр таба икән, аларны бетерә ала һәм яхшы гадәтләрне үзендә булдыра ала.

Үз-үзеңне тәрбияләгәндә иң элек тормышның билгеле нык тәртибен булдыру, дөрес режим тоту шарт. Тормыш тәртипле булганда бик күп нәрсәләргә өлгерергә була: яхшы укырга да, спорт белән шөгыльләнергә дә, һәвәскәр түгәрәкләргә йөрергә дә, кызыклы китаплар укырга да, өйдә әтиәнигә ярдәм итәргә дә вакыт табыла. Шул ук вакытта йокларга ятканда рәхәт арыганлык сизәсең, иртән билгеле бер вакытта уянуга сикереп торасың, бу һич кирәкмәгән уй-хыяллар белән мавыгырга урын калдырмый, димәк, кешедә сәламәт әхлак тәрбияли дигән сүз.

Бу гадәтне булдыру һәр кешенең кулыннан килә һәм бары тик үзеннән генә тора.

«Ялкаулык — һәр бозыклыкның анасы»,— дигәннәр борынгылар. Эшкә өйрәнү — киләчәк гаилә тормышына өйрәнү ул, эшчәнлек, уңганлык мәхәббәтне ныгыта. Кызларга яшьтән үк өй карау эшенә, аш-су пешерергә өйрәнү бик кирәк. Исегездә тотыгыз: яшь гаиләләрдә күп низагларга хатыннарның өй эшенә кулы ятмавы сәбәп була.

Башкаларның хәленә керү, ярдәмчел, игътибарлы, йомшак мөгамәләдә булу бигрәк тә хатын-кызларга хас һәм кирәк сыйфатлар. Һәр очракта да принципиаль булам, дип каты күңелле булудан сакланырга кирәк.

Кешенең тормышка әзерлеге — мәхәббәткә әзерлеге дә ул. Мәхәббәткә әзерлек кешенең бөтен физик һәм рухи үсешен эченә ала.

Менә шулай: ярата белү ул — өзми-куймый күңелең төшкән егет турында гына уйлап, авырыга сабышып йөрү дигән сүз түгел. Ярата белү өчен иң элек гаилә тормышына әзерлекле, кешелекле, күркәм холыклы булу кирәк.

Мәхәббәтнең чыны үсмер чакта ук ашыгып килмәскә дә мөмкин. Үз вакыты белән килер ул. Ләкин ничек килер бит! Берәүләргә бәхет-сөенечләр алып килсә, икенчеләргә җан газаплары алып килә бит ул мәхәббәт дигәнең.

Мәхәббәтнең ничек килүе күп очракта кешенең аны нинди әзерлек, нинди рухи байлык белән көтеп алуына бәйле була.

Баһрам САДЫЙКОВ,
медицина фәннәре докторы.



ДӘҮ ӘНИ, ДӘҮ ӘТИ

Мин Югары Масра авылында мәктәп директоры булып эшләдем, шунда тормыш иттем.

Күршем Мөхәммәтша бабайның гаиләсе ишле иде. Карткарчык балаларын тәртипле итеп үстерделәр, укыттылар. Бик әйбәт, кешелекле кешеләр иде. Балалары да үзләренә охшадылар, ата-анага тормыш йөген тартырга булыштылар. Тормышлары матурайгач кына, озак авырудан соң, әтиләре дөнья куйды. Аны зурлап соңгы юлга озаттылар. Өлкән уллары, үзе кебек уңган авыл кызына өйләнеп, төп йортта калды. Тол калган әни карчыкны уллары-киленнәре, кызлары-кияүләре дә бик олылыйлар, тәрбиялиләр. Әни карчык үзе дә чиста, пөхтә, кояш кебек ягтырып кына сөйләшә торган тере карчык. Йортта аш-су әзерләргә, һәр эшкә житешә. Ялгыз-япак күршеләренә булышырга да өлгерә. Аз гына авырып китсә, күрше-күлән дә аның хәлен белешә тора.

Улы Габдрахман, килене Кафия белән бергә тату гомер итәләр. Килен белән каенананың киңәш-табышлары бергә. бер-берсенең сүзеннән чыкмыйлар.

Көтмәгәндә әни карчыкка борчу килеп чыга. Казан шәһәрендә яшәүче олы кызлары, бәхетсезлеккә очрап, яшь бала белән кала. Шул чак киң күңелле килене Кафия бу баланы карарга үзенә алып кайта. Тормыш булгач болай да эш күп, шулай да Данисны яратып, җиренә җиткереп карарга да житешә. Каенсеңеленең дә хәсрәтен уртаклаша. Бала мондый шартта әйбәт үсә, дәү әни, дәү әти, әби дигән сүзләр белән теле ачыла. Бала инде үсә төшкәч тә якты йөзле, тәмле сүзле дәү әнисен, дәү әтисен, уйнап үскән күрше малайларын калдырып, шәһәргә китәсе килми. Данис, мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының химия-биология факультетына укырга керде.

Данисны мин мәктәптә сигез ел укыттым. Ялга кайткан вакытларында янымa — пенсиядәге укытучысына кагылмый китми.

Хәзер әнисенең Казанда үз квартирасы бар. Данис та шунда, әнисе янында торып укый. Үз әнисен, үстергән дәү әнисен, дәү әтисен, тәрбияләгән әбисен дә бик якын итә, үз күрә. Ялга кайткан чакларында дәү әнисенә булыша. Уйнап үскән иптәшләре белән аралаша. Олыларны олы итә.

Мин хәзер 58 яшьтә, шуның 36 елын яшь буынны тәрбияләүгә бирдем. Төрле семья, төрле ата-ана белән очрашырга туры килде. Ата-аналардан уңай һәм тискәре фикерләр ишеткән чаклар да булгалый. Семьяда бер генә бала үссә, ул иркә, шаян, үз сүзле, тәртипсез була, дигән ялгыш фикерләр бар. Мин яшәгән кечерәк кенә авылда, ирләре сугышка китеп, 20—22 яшьләрдә берәр малай белән калган ярты дистәдән артык ана бар. Үз намусларына турылыклы булып, сугыш, аннан соңгы авыр елларда үстергәннәр алар балаларын. Ул малайларны да укытырга туры килде миңа. Яхшы укыдылар, тәртипле булдылар. Хәзер бу балалар семьялы, заманча яхшы йорт-җирле. Үстергән әниләрен йортларының күрке итеп тоталар. Күбесе механизаторлар. Үз колхозларының төп таянычы алар.

Балаларын дөрес тәрбияләгән ата-аналар мәктәптәге эшләргә дә зур йогынты ясыйлар, алар укытучы халкының иң яраткан дуслары булып торалар. Йомгаклап шуны әйтәсем килә: бала гаиләдә нинди тәрбия ала, ул шул юнәлештә формалаша. Димәк, бу балаларны үстергән ата-аналар, әбиләр үзләре тәртипле булганнар.

Госман БИКБАЕВ,
Арча районы, Югары Масра авылы.



Укытучы

Кайчак шулай була. Бер күрү белән үк кешене якын итәсең, үзенә карата тирән ихтирам хисе туа. Андыйлар белән тиз генә уртак сүз табыла. Озак та үтми, бу кешене күптән белем түгелме соң мин, дип уйлый башлыйсың.

Әминә Гарифовна белән без Яңа Зәйдәге 3 нче мәктәптә очраштык. География дәресенә керәсем килүне әйткәч, мәктәп директоры:

— Рәхим итегез. Әминә Гарифовна шатланып каршылар, — диде.

Әйбәт дәресләр, проблемалы укыту, балаларның иҗади хезмәтен оештыручы күркәм укытучылар турында аз язылмый, аз сөйләнми. Ләкин шуларны үз күзең белән күрү, үз колагың белән ишетү бөтенләй башка нәрсә.

Әминә Гарифовнаның бишенче класстагы дәресе «Атмосфера явым-төшемнәре» дигән темага багышланган иде. Бишенчедә, билгеле булганча, яшүсмерләр укый. Балаларның тәрбиягә иң кыен бирелә торган чагы. Әгәр аларның психологиясен, яшь үзенчәлеген әйбәт белмәсәң һәм истә тотмасаң, күпме генә тырышып хәзерләнсәң дә, дәресеңнең «челпәрәмә килүе» бик ихтимал. Менә бер мисал. Яшүсмерләрнең үзләрен зур итеп санийсылары килә. һәм бертуктаусыз үзләренә «балалар» дип тәкърарлап торуны бер дә яратмыйлар. Вакытлары җитәме, юкмы, даими рәвештә телевизор тапшыруларын карыйлар, әллә никадәр газета-журналлар, матур әдәбият китаплары укыйлар. һәм менә шушы укучыларга коры дәреслек материалын гына сөйләп кара син. Тыңласалар ярый, ә бит тыңламаулары да бик мөмкин. Яшүсмерләрнең яңгыр, кар, боз яуганны, томан, чык төшкәнне бик күп күргәннәре бар. Бу хакта сөйләп аларны гаҗәпләндереп булмый. Табигать күренешләрен фәнгә нигезләп, шул ук вакытта укучыларга барып җитәрлек итеп аңлатырга, дингә каршы тәрбия чарасы итеп файдаланырга кирәк иде.

Әминә Гарифовна проблемалы сораулар кую юлы белән теләгенә ирешә. Укучылар дәрес материалларын ныклы үзләштерү белән генә чикләнмәделәр, философик сорауларга да (материя беренчел, аң икенчел) җаваплар таптылар.

География практик эшчәнлек, объектив дөнья күренешләре белән тыгыз бәйләнгән. Моны оныттыңмы — уңышсызлыкка очравыңны көт тә тор. Шуңа күрә укытучы бик күпне белергә, күп укырга, бүгенге көн фәненең сулышын туктаусыз тоеп барырга, балаларның тирә-юнь белән кызыксынуын үстерергә, укытуның иң нәтиҗәле алымнарын файдаланырга тиеш.

Хәзер искә төшерүе дә күңелсез. Әминә Гарифовна бу мәктәптә укыта башлагач (моннан 12 ел элек), шуны сизеп алды: балалар туган як белән бөтенләй кызыксынмыйлар диярлек. Бу кайдадыр түгел, Зәй якларында лабаса! Урман дисеңме, су дисеңме, бар да бар. Бөтен Европага атаклы Зәй ГРЭСының торбалары күккә тиеп тора. Ерак та түгел, мәһабәт Кама елгасы дулкыннарын ярга кага. Якташыбыз атаклы рус художнигы И. Шишкин тасвирлаган урманнар да күршедә генә. Үзебездә нефть дәрьясы. Ә балаларның моңа исе китми. Ләкин бу хәлгә алар гаепле түгел иде.

Укучыларның «дөньяга күзен ачу» — укытучылар бурычы. Әминә Гарифовна үзенең эшен әнә шул юнәлештәрәк баш-

Дуслар очрашкач

Үзем белән үзем бәхәсләшеп тагын күпме йөргән булыр идем, белмим, таныш рәссамны очраттым. Белем: драматург Туфан Миңнуллинның һәр әсәре белән ул да танышып бара. Ул кичтә без бик озак сөйләшеп йөрдек.

— Эч пошып тора әле: үземдә үсеш, үзгәреш сизмим, гел бер урында таптанам сыман. Дөньяны матурайтасы, дусларны сөендерәсе килә, — ди рәссам.

Мин аңа карап көлеп җибәрми булдыра алмадым. «Дуслар җыелган җирдә» спектаклен карадым дисең инде ә-ә! Нәкъ Нурислам кебек сөйлисең!» — дим.

— Юк, карамадым, өлгерә алганым юк әле. Нәрсә, Нурислам белән минем арада охшашлык бармыни!

— Нурислам — синең яшьләрдәге рәссам. Яңа картинасын күрсәтер өчен, дусларын остаханәсенә чакыра. Алар картинаны күкләргә чөеп мактыйлар. Ләкин рәссам үзе канәгать түгел. Аның дусларыннан: «Бу картинаң барып чыкмаган бит», — дип әйттерәсе килә.

— Бәлки аның дуслары на картина чыннан да ошыйдыр! Кемнәр соң ул дуслар!

— Химик Гайнулла, шагыйрь була алмагач, галим булып киткән Рәфис, популяр җырлар иҗат итүче Фәһим, аларның хатыннары һәм Миләүшә. Дуслыклары күптәннән килә. Тамашачы аларны «Миләүшәнең туган көне» спектаклендә бер тапкыр күргән иде инде. Ләкин «Дуслар җыелган җирдә» әсәре үзенә бер бөтен. Биредә Гайнулла гына яңа кеше, ул бу даирәгә моннан ун ел элек кенә кергән.

— Ун ел — аз гомер түгел. Ярый, анысы калып торсын. Димәк, болар арасында рәссамнар да, сәнгать белгечләре дә юк. Аларның картинадагы җитешмәгән якларны күрә алмавы да мөмкин. Икенчедән, рәссам, рәсемен дуслары тәнкыйть итә дип кенә, аны төзәтә алмый бит.

— Нурислам үз иҗатына объектив бәя бирә белә. Ул бу җәһәттән дусларына караганда алда тора. Аны хәзер үз иҗаты гына түгел, дусларының яшәү ысулы, дөньяга карашы да борчый. Уйланмыйлар, эзләнмиләр, тыныч кына гомер сөрәләр. Иҗат кешеләрен үтерә торган канәгатьлелек башланган. Нурислам үзен борчыган уйларны әкият итеп дусларына сөйли. Ике бөкере егет булган, имеш. Шуларның берсе үз фикерен әйтмичә, пәриләргә кушылып алар сүзен кабатлаган һәм бөкересеннән котылган. Икенчесе пәриләргә каршы чыккан, үз фикерен әйткән һәм аркасында тагын бер бөкере арттырган.

Нурислам дусларын ярым йокы хәленнән чыгарырга тели. һәм рәссам шуңа ирешә дә. Өч гаилә төне буе керфек какмый бәхәсләшеп чыгалар. Нурислам белән Миләүшә дә бәхәсләшеп төн уздыралар. Дуслар уяндымы! Ничек кенә әле! Таң алдыннан барысы да шул ук остаханәдә җыелалар. Рәссам шат, чөнки ул максатына ирешә, дуслары уянды.

— Картина ни хәлдә!

— Нурислам картинаны ертып ташлый.

— Бусы — акыллы кеше эше түгел, рәссам үз әсәрен ерта алмый, ул бит аның йөрәк җимеше. Начар чыккан икән, ап-акка буя да шул ук киндергә яңа рәсем яса!

— Мин үзем Нурисламның картинасын юкка чыгаруын хуплыйм. Шулай да, минем карашымча, Нурислам образында бәхәсле сыйфатлар да бар. Миләүшә белән мөнәсәбәтләре

ХЕЗМӘТЕ

лап җибәрде. Еллар буенча урнашкан бертөрлелекне, тирә-юньгә ваемсыз карашны вату җиңел булмады. Ләкин кыенлык алдында тукталып калу бу укытучыга хас нәрсә түгел иде. Мәсьәлә анда гына да түгел. Совет укыту системасы теорияне коммунистик төзелеш практикасы белән бәйләп алып баруны таләп итә, икенче төрле әйткәндә, аның хәлиткеч принцибы, нигез ташы булып тора. Ләкин моны да бер яклы гына итеп, җирле материалга табыну дип кенә күз алдына китермәскә кирәк. Бөек рус педагогы К. Д. Ушинский образлы итеп болай дигән иде: «Укытучы таныштыра торган җирле елга үзенең агымы белән баланы якын-тирәдән Ватан киңлекләренә алып чыгарга тиеш». География фәненә хас әнә шул принципны иптәш Халикова үзенең көндәлек эшчәнлегендә туктаусыз тормышка ашырып бара.

Шуны да онытмыйк, укучыга белем-тәрбия нигездә дәрестә бирелә. Ун ел эчендә укучы 11 меңгә якын дәрес тыңлый. Нәкъ шул чакта аның дөньяга фәнни-материалистик карашы формалаша. Ә бу искиткеч әһәмиятле нәрсә. Чөнки кешенең дөньяга карашы нинди — ул үзе дә шундый.

Әмма дәресләр барыбер укытучы эшчәнлегенең бер генә ягы ул. Укытучыларның иң зур күпчелеге — класс житәкчеләре. Моннан тыш төрле җәмәгать эшләре дә педагог җилкәсенә төшә. Бу яктан Әминә Гарифовна иптәшләреннән аерылмый.

Ул оештырган география түгәрәге членнары тирә-юньне, аның табигый байлыкларын өйрәнү теләге белән бик күп экскурсияләргә, сәяхәтләргә йөрделәр. Моннан соң туган як тарихы белән танышу теләге туды. Тукталып калмадылар. Йөзләрчә кешеләр белән сөйләштеләр, документларга мөрәҗәгать иттеләр. Тырыш хезмәт туган як тарихы почмагы ачып җибәрергә мөмкинлек бирде. Музейда даими очрашулар үткәрелә. Соңгы вакытларны гына да укучылар алдында Татарстанның атказанган врачы М. Никифоров, КПССның XXV съезды делегаты О. Макарова, милиция хезмәткәрләре чыгыш ясады. Мондый сөйләшүләрнең укучыларга уңай йогынтысын бер нәрсә белән дә чагыштырып булмый.

Әлеге класс җитәкчесенең эше белән таныш булмаган ата-ананы табуы кыендыр. Һәркайсы аның белән бәйләнешкә керә. Балаларын бергәләп тәрбиялиләр. Ләкин балалар кебек, ата-аналар да шактый төрле булалар. Әминә Гарифовна мондый хәлне хәтерли. Бер ана малаен, әгәр иптәшләре белән килсә, өеннән куып чыгара, иданне таптыйсыз, мебельне пычратасыз, дип ачулана икән. Нишләсен бала. Нәүмиз булып чыгып китә. Аңа иптәше алдында бик уңайсыз. Алай да, әни куа дип, иптәшләрсез торырга җыенмый малай. Кем белә, менә нинди иптәшләргә очрар бит әле ул?

— «Киемгә табынучы» ата-аналар белән эшләве дә җиңел түгел, — ди Әминә Гарифовна. — Андыйлар, безнең балалар кешенекеннән ким булмасын, дип тырышалар. Һәм өстенлекне балага уку шартлары тудыруда түгел, бәлки затлы кием алуда күрәләр. Шуның белән үзләренчә бала күңелендә мәхәббәт уялыйлар. Бик тә ялгышалар.

Әлбәттә, иптәш Халикова югарыда әйтелгәндәй ата-аналар белән махсус эш алып бара. Нигездә уңышка ирешә.

Укытучы хезмәте. Ул хакта китаплар язылган. Кинокартиналар да бар. Ләкин беркем дә, менә мин укытучының бөтен эчке һәм тышкы дөньясын ачып салдым, дип әйтергә батырчылык итмәс. Чөнки бу хезмәт — иҗади эш. Заман таләпләренә туры китереп алып барыла торган җитди хезмәт ул. Татарстанның атказанган укытучысы коммунист Әминә Гарифовна Халикованың 30 еллык педагогик хезмәтенә бәя биргәндә дә әнә шуны истә тотарга туры килә.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,
педагогия фәннәре кандидаты.

Тамашачы фикере

аңлашылмый. Егетлек күрсәтәсе урында, ул Миләүшәне күтәреп өстәлгә бастыра да: «Җырла!» — ди. Үзе өч метр ераклыктан аңа карап тора. Үзе, сине яраттым, башкалар белән пычранасым килмәде, дигән була. Авыр һәм аңлаешсыз сүзләр. Башка төслерәк итеп әйтеп булмас идеме икән! Ник Миләүшә чиста, башкалар пычрак әле! Мин ул көнне бу спектакль турында озак сөйләдем, янымнан акрын гына атлаган рәссам кат-кат сораулар бирде. Әгәр миңа тын бер кечтә химик очраса, Ә. Шакиров башкарган Гайнулла, университетта укытучы очраса, Р. Шәрәфиевнең — Рәфисе, хәтта Ирек Баһмановның Фәһиме турында бик озак һәм рәхәтләнеп сөйләшер идем.

Туфан Миңнуллин гыйбрәтле пьеса язган. Режиссер М. Сәлимҗановның да драматург белән тамашачы арасында оста һәм талантлы арадаш булуы күренә. Тамашачы уйлана. «Менә нинди булырга тиеш икән безнең заманның иҗат кешесе. Заманыңа лаек булырга теләсәң, акны карадан гына түгел, акны актан, караны карадан да аера белергә кирәк икән».

Гөлсинә ВӘЛИӘХМӘТОВА.



Спектакльдән бер күренеш.
Эльмира ролендә Фирдәвес Әхтәмова, Фәһим — Илдус Әхмәтҗанов.
Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотосы.

«ЧАЯН»

Суфия НАСЫЙРОВА рәсеме.




Сүзсез.

Светлана ПРИВИНА рәсеме.



— Менә сиңа тамаша! Ә бит гап-гади тарелкалар ыргытудан башлаган иде.

Суфия НАСЫЙРОВА рәсеме.



— Әнием, әнием, ә мин балыкны иң салкын урынга куйдым.

ӘНИ КУНАККА КИТКӘЧ

Юмореска

Бердәнбер улы Әптәз үкереп елап кайтып кергәч, Әкмәл абыйның да күзләре яшьләнде.

«Шул инде, — дип уйлады ул эченнән генә, — кая барсаң да, әнисез баланы рәнҗетәләр. Әнисен әйтер идем, баланы ялгыз калдырып, өчәр көн кунак булып ята. Ну, бу хатын-кызны!..»

— Ашарга китеримме, улым?

— Бәйлән-мә... — дип иңнәрен калтырата-калтырата елавын гына белде Әптәз.

— Күлмәгеңне алыштыр, улым. Чалбарыңны да сал. Үтүкләп куярмын.

— Бәйләнмә, дим!..

Ни булды соң, улым, ни булды, бәбкәчем минем? Кайсы таш бәгырьлесе рәнҗетте икән син багалмамны. Әниең кайтсын әле менә. Әйрәтербез без аларны, кирәкләрен бирербез!

Әптәз, чишенеп-нитеп тормыйча, мамык түшәккә ауды. Шулай йөзтүбән яткан килеш, мендәр читен чәйни-чәйни елады ул.

— Улым, багалмам, әйт инде, ни булды соң, ни генә булды? — дип кровать тирәли бөтерелеп йөрде Әкмәл абый.— Бәлки, берәр рюмка коньяк эчәрсең, улым, ә?..

— Не приставай миңа!

— Булмаса, берәрне кәйрәтеп җибәрик, улым, бәлки, җиңеләеп китәр.

— Кит, дим!..

— Улым, улым, карале, нинди матур гитара сатып алып кайттым мин сиңа...

— Ә-ә-ә... У-у-у...

— Әйдә, улым, әйдә, чишен. Ваннада җылы су бар. Юындырып алам үзеңне.

— Эч пошырма-а-а...

— Улым, я, җитәр инде, тынычлан. Кеше ишетә бит, улым, яхшы түгел...

— Ишетсен... Все равно жить не буду бу дөньяда-а-а-а... повешусь... суга төшеп үләм... Пазоры гына-а-а ни тораа-а-а...

Әкмәл абый түзмәде. Тамагына килеп тыгылган кайнар төерне йотып җибәрде дә, улы өстенә капланып, үксергә кереште. Ул Әптәзнең пеләшләнгән баш түбәсен, мыекларын, йонлы күкрәкләрен сыйпады. Ә үзе бертуктаусыз: «Эх, әниең өйдә булса, эх, әниең өйдә булса»,— дип такмаклады.

ТОР, ҖҮЛӘР!..

Завод ихатасыннан чыккач, Сабитка сабакташлары очрады. Кафега кереп утыргач, сүз иярә сүз кузгалып, сыра артлы сыра китертелеп, кәефләнә торгач, Сабит шактый мөлҗәрәде һәм өенә соң гына кайтты. Хатыны йоклый иде, ахры — өйдә тавыш-тын юк. Туфлиләрен, өс киемнәрен салгач, Сабит дүрт аякланып бишек янына килдә һәм:

— Әлли-бәяли-бәяли-бәү! — дип бишекне тирбәтә башлады.

Көйләү-мырлау тавышына Сабитның хатыны уянды, күзләрен шарландырып:


— Ни кыланасың анда? — диде.

— Ана түгел, йокы чүлмәге син! Сабый елый, ә мин кичтән бирле тирбәтеп утырам,— дип мыгырданды Сабит, ачулы булырга тырышып.

— Тор җүләр! — диде хатыны.— Бала бүген бишектә түгел, минем янда, караватта ята...

Радик МУЛЛИН.

Лия БОЧКОВА рәсеме.



— Этегезне борынлыксыз йөрткән өчен судка бирәм бит мин сезне!

КӨЛЕГЕЗ!..

Рәшит ЗӘКИЕВ,
«Чаян» журналының баш редакторы.

Кызлар бүрәнә ярыгыннан да көлә, дигән әйтем бар.

Хатын-кызларның күңел көрлеген, җор сүзне, шаянлыкны яратуларын, минемчә, үтә тапкыр һәм ягымлы итеп сурәтли бу әйтем. Чынлап та, аларның елмаюыннан-көлүеннән башка тормыш нинди төссез, салкын булыр иде.

Яратып көлү бар, усал көлү, үртәп көлү, мыскыллап көлү бар. Хатын-кызлар аның төсмерләрен бик яхшы сиземли һәм, кирәк чагында, искиткеч оста итеп эшкә җигә. Чыдасаң — чыда, чыдамасаң көл дә... ела.

Шаянлыкны, үткен һәм тапкыр сүзне юлдаш иткән кешеләр, билгеле, «Чаян» журналына битараф кала алмыйлар. Алай гына да түгел, «Чаян»ның ярты миллион укучыларының зур күпчелеген йөзләрендә елмаю нуры балкып торган хатын-кызлар тәшкил итә.

«Чаян» авторлары арасында, һәм язучылар, һәм шагыйрьләр, һәм рәссамнар буларак, даими рәвештә хатын-кызлар катнашуы безне аерата сөендерә.

Җыеп әйткәндә, бүген «Азат хатын» журналы үзенең иске дусты, ут күршесе «Чаян»ны кунакка дәшә. Бу бик табигый хәл.

«Азат хатын» укучыларына тәкъдим ителә торган әсәрләргә һәм авторларга аерым-аерым характеристика биреп тормастан, көлү остасы булган бер шагыйребезгә кушылып: «Көлегез, көлегез, файдасы күп — белегез!»—дип кабатлыйм.

ЖУРНАЛЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

Ата белән бала, шулай бер-берсен кочаклап, бик озак елаштылар.

Ниһаять, Әптәз тынычлана төште. Торып утырды Иңбашлары әллә нигә бер генә сикергәләп куя иде аның хәзер. Әкмәл абый пинжәк чабуы белән улының керфекләре арасыннан сыгылып-сыгылып чыккан энҗедәй саф яшь бөртекләрен сөрткәләп торды.

— Менә шулай, менә шулай, улым. Җылама, җәме. Җылама. Озакламый әниең дә кайтыр, алла боерса. У-у... бәреп кенә үтерер идем... Кайсы юньсезе тиде икән минем бердәнберемә?..

Әптәз:

— Әсмабикә!— дип ачыргаланып кычкырды һәм янә мендәргә капланды.

— Кайсы Әсмабикә, улым?

— Который практикага килде... а-а-а...

— Нишләтте, улым, нишләтте Әсмабикә сине? Кимсеттеме? Хатын аерган-сың, дидеме? Әлиминт түлисең, дидеме?..

— Обманула-а-а... Сначала каш сикертеп башымны әйләндереп йөрде... А теперь әйтә, что Уфада ирем белән малаем бар... уа-уа-уа...

Фаил ШӘФИГУЛЛИН



— Тынычлан, зинһар. Моны бер зиһенсезе трамвайда онытып калдырган...

Хәниф ХӨСНУЛЛИН

ҮЗЕНӘ ИПТӘШКӘ


Авыл урамында ике хатын сөйләшә:

— Карале, күршекәй, сезнең казыгыз бөбкәләр чыгарган дип ишеттем, ничәү булды инде җыенысы?

— Ике ояга уналты бөбкәбез бар.

— И, бик әйбәт булган. Безнең бер генә оя. Унҗидедән баса. Болай йомыркалары әйбәт күренә. Шулай да бик күпне өмет итеп булмас. Ана казны әйтәм, үзенә иптәшкә уналтыунҗиде бөбкә чыгарса, бик җиткән инде.

Нәҗип МАДЪЯРОВ.



ЯРЫЙ, КАРЧЫК

Гамил АФЗАЛ

...И, дускаем, сиңа бәян итәм:
Юаш ир дә алтын түгел икән.

Кешеләрнең ире эчеп кайта,
Гайрәт белән табак-савыт вата.

Ә минеке телевизор карый,
Бер сүзе бар: — «Ярый, карчык, ярый».

Йөгереп йөрәп кул-аяклар арый,
Булыш, димен. — «Ярый, карчык, ярый».

— Әзрәк селкен инде, Габделбарый!
Селкенми дә. — «Ярый, карчык, ярый...»

Кичләр буе безнең Габделбарый
«Ну, погоди!» дигән фильм карый.

Туктале, дим, гамьсез, кино-мескен,
Сабыр кузең маңгаеңа менсен!

— Мин гашыйк булдым, — дим, —
Габделбарый —
Барый әйтә: — «Ярый, карчык, ярый».

— Йортка кияү кертәм, Габделбарый!
Барый әйтә: — «Ярый, карчык, ярый».

Габделләхәт килде, бирнәсе — бер шешә,
һәр борынга бер стакан төшә.

Кутәрделәр чәкеп ямьле генә,
Героик хатын-кызлар исәнлегенә.

Габделләхәт белән Габделбарый
Хәзер парлап телевизор карый...



— Кемдер безнең фатирда калдырып киткән.

АНДЫЙ КЕШЕ

Сораудан башлыйм сүзне:
Кайсыгыз нурлы йөзле!
Егетләр булса — дәшмәсен,
Ә кызлар булса — әйтмәсен,
Сорау да бушка китмәсен.
Сорап карыйм тагын бер:
Кайсыгыз бик ягымлы!
Егетләр булса — дәшмәсен,
Ә кызлар булса — әйтмәсен,
Сорау да бушка китмәсен.
Тагын сораудан китәм:
Кайсыгыз бигрәк эшчән!
Егетләр булса — дәшмәсен,
Ә кызлар булса — әйтмәсен,
Сорау да бушка китмәсен.
Җавап юкмы!..
Хәбәр итәм:
Андый кеше —
Минем иркәм.

Заһирә ГОМӘРОВА

ШАП!

Бер ханым, әй, бүген эшкә
Маңгае күбеп килде.
Күңелсез хәл нәтиҗәсе,
Әлбәттә, мондый билге.

Сүгәбез ирен ханымның:
— Әй, каһәр суккан,— дибез,—
Тамчы да аяп тормаган,
Бик зәһәр суккан,— дибез.
— Нинди чибәр хатынының
Кадерен белми,— дибез.—
Беркөн үкенер,— дибез,—
Гафу үтенер,— дибез.

Ә бераздан белдек барын:
Әлеге чибәр ханым
Күршесенең ишегенә
Куйган икән колагын...



КУЛЛАНА БЕЛСӘҢ ГЕНӘ

Төрле химик препаратлар безнең йорт мәшәкатьләребезне бик нык җиңеләйтәләр. Идән юганда да, кер юганда да, өй җыйганда да, ванна, савыт-саба чистартканда да кулланабыз без аларны.

Ләкин аларны куллана белеп кулланырга кирәк. Кагыйдәләрне бозсаң, файда күрү урынына бәла-казага таруың бик мөмкин.

Иң беренче чиратта аларны саклау өчен билгеле бер урын булдырырга кирәк. Ул урынга балаларның буе җитәрлек булмасын. Гомумән, балалы йортта андый препаратларны саклау өчен бикләнә торган аерым шкаф булдыру яхшы. Әлбәттә инде, химик препаратлар кухня тирәсеннән ерак торырга тиеш. Химик препаратларны сөт шешәләренә, банкаларга бушатырга ярамый, чөнки болай итсәң, аларны бербересеннән һәм азык-төлектән аерып алу кыенлаша. Һәр препаратны үз савытында, кәгазе ябыштырылган килеш, капкачын нытып ябып сакларга кирәк.

Кызганычка каршы, кайбер очракларда һәркем кулыннан килерлек бу гади кагыйдәләр бозыла һәм өйдәге химик препаратлар белән агулану очраклары булып тора.

Бигрәк тә төрле кислоталар һәм селтеләр белән агулану куркыныч. Андыйлардан өйдә каустик сода, нашатыр спирты, аш серкәсе, азот һәм тоз кислоталары була. Тутыкны бетерә торган препаратлар составында кузгалак һәм кырмыска кислоталары бар.

Әгәр кеше ялгышып күе кислота эремәсен яки селте йотса, аның йоткылыгы һәм үңәче, сулыш юллары яна, җилсенә, күп микъдарда төкерек бүленеп чыга, сулыш алу авырая, җилсенгән әгъзалар бик нык авырта. Кислота тигән урында тән тиресенең дә җәрәхәтләнүе ихтимал.

Ацетон, скипидар, БФ җилеме, лакларны бетерә торган эремәләрне йотсаң, тамак авырта, күңел болгана, эч китә. Еш кына бөерләрнең эшчәнлеге бозыла, бәвел килү туктый. Бу препаратлар кешене исертеп тә җибәрәләр, агуланган кеше ярсыган була, кайчак медицина ярдәменнән дә баш тарта. Әгәр агулану көчле булса, көзән җыерырга һәм һушсыз калырга да мөмкин.

Химик препаратлар белән агуланган һәр очракта һич кичекмәстән «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырырга кирәк.

Агуланган кешене яткырып, мамык, марля яки чиста кульъяулык уралган бармак белән аның авыз куышын тазартырга кирәк. Кайчак, авыруның сулыш алуы бик авырайса, «авыздан-борынга» ысулы белән ясалма сулыш ясарга кирәк була.

Әгәр кеше косса, бигрәк тә кан косса, аңа бер яки бер ярым стакан су эчерергә кирәк. Ләкин суны аннан да күп эчерергә ярамый. Су ашказанындагы агуны сыеклатып, аның зарарын киметә. Коскан кеше тончыкмасын өчен, аны кырын яткызу яхшы.

Кислота яки селте белән агуланган кешенең ашказанын юдырырга һич ярамый. Шулай ук кислота белән агуланган кешегә селте бирү һәм селте белән агуланган кешегә кислота бирү куркыныч. Чөнки андый очракта ул химик сыекчалар кушылып, реакция була, газ, җылылык бүленеп чыгу нәтиҗәсендә эч күбә, күңел болгану, кан килү көчәя.

Ацетон, скипидар, БФ җилеме һәм лакны бетерә торган эремә белән агуланган кешенең ашказанын шунда ук юдырырга кирәк — моның өчен аңа өч-биш стакан җылымса су эчереп, авызына бармак тыгып косторалар.

Авыруның эченә боз яки салкын су салынган куык куялар, аңа торып йөрергә рөхсәт итмиләр.



САКЛАНЫРГА КИРӘК БУЛСА

Кайбер авыру кешеләргә майлы ит, кыздырылган, артык майлы ризыкларны ашарга киңәш ителми, ә шикәр чире белән чирләүчеләргә баллы-татлы ризыклар ашау да тыела.

Андый кешеләр өчен ризыкны аерым, махсус пешерергә туры килә. Без диета ашларының берничәсен тәкъдим итәбез.

КӘБЕСТӘ ШУЛПАСЫ

Кайнап торган суга туралган кәбестә салалар. Пешеп җитәргә 5—7 минут кала майда кыздырылган кишер һәм помидор яки томат өстиләр, тоз салалар. Табынга куяр алдыннан петрушка яки укроп яфраклары сибәләр, каймак салалар.

300 г ашка — 20 г кишер, 10 г помидор яки 1 бал кашыгы томат, 5 г акмай, 15 г каймак, 5 г яшел тәмләткечләр кирәк.

ИТЛЕ КӘБЕСТӘ КАТЛАМАСЫ

Пешкән итне иттарткычтан үткәрәләр, башлы кәбестәне турыйлар, сөт өстәп, ябык савытта йомшарганчы пешерәләр. Аннары, болгата торып, манный ярмасы өстиләр һәм тагын 5—10 минут пешерәләр. Кирәгенчә тоз өстиләр, йомырка салып, яхшылап болгаталар. Майлы табага (яки формага) кәбестәнең яртысын салалар, өстен тигезлиләр, аңа итне салалар, әз генә тоз сибәләр, өстенә калган кәбестәне җәяләр дә, мичкә куеп пешерәләр. Табынга куяр алдыннан өстенә май сибәләр.

ШИКӘРСЕЗ ДӘ ТАТЛЫ РИЗЫКЛАР

Кайбер авыруларга шикәрне бөтенләй ашарга ярамый яки бик аз микъдарда ашарга киңәш ителә. Андый очракларда шикәр урынына ксилит яисә сорбит кулланалар. Ксилитны шикәр кебек үк кулланырга була, сорбитны исә ксилитка караганда икеләтә күбрәк салырга туры килә,



ПӨХТӘЛЕК КЕШЕНЕ БИЗИ

Капрон һәм эластик оекларны, колготкиларны кибеттән алып кайткач, кигәнче җылы суда юыгыз, әмма борып сыкмагыз, сөлгегә урап корытыгыз. Оекларны бөкләп бауга элеп киптерергә ярамый, очыннан кыстыргыч белән эләктереп киптерү яхшы. Оекларны көн саен юарга кирәк.

* * *

Туфли каешларыннан һәм олтаныннан йоккан кара таплар бетсен өчен, нейлон һәм капрон оекларны юар алдыннан ярты сәгать элек сабынлап кую әйбәт.

* * *

Күзе сүтелеп киткән оекны пары белән чыгарып ташларга ашыкмагыз. Сыңары ертылып та икенчесе бөтен калган оеклар арасыннан сыйфаты һәм үкчә формасы белән охшашларын пар-пар итеп сайлап алыгыз. Аларның төсләре төрле булырга да мөмкин. Оекларны бер төскә кертү өчен «Элегант» дигән буяуга манарга була. Ул буяу хуҗалык кибетләрендә сатыла. «Элегант»та оекларны озак тотсаң, төсе — караңгырак, әз тотсаң, ачыграк була.

* * *

Ак туфли һәр хатын-кызга килешә, аны теләсә нинди күлмәк белән киеп була. Тик шунысы бар — ак туфли тиз тузанлана, керләнә. Аны чистарту кыен, иң яхшысы — юу. Ак туфлины сабынлы суга манчылган йомшак щетка яки поролон кисәге белән тиз генә ышкыйлар, чиста җылы су белән сабынын юып төшерәләр һәм чиста чүпрәк белән корытып сөртәләр. Туфли кипкәч, төссез гуталин яки «Сочи» дигән крем белән чистартып ялтыраталар. Шулай итсәң, туфлигә яңа төс керә.

* * *

Күлмәккә балык консервысының мае тамса, бик ямьсез тап калдыра. Аны юып бетерү кыен. Ләкин аннан котылуның бик ансат кына чарасы бар: майлы тапка теш порошогы сибәләр, өстеннән баскалыйлар да төнгә шул килеш калдыралар. Акбур майны үзенә сеңдереп ала. Иртән порошокны кагып төшерәләр дә, щетка белән сак кына чистарталар.

* * *

Алкалар, төймәләр, йөзек-беләзекләр, хатын-кыз-

Әгәр кислота күзгә яки тән тиресенә тисә, аны краннан яки чәйнек борынынан аккан су белән юдыралар. Чүпрәк белән сөртергә ярамый, чөнки ул чакта кислота тәнгә сеңеп, яну көчәя.

Агуланган кешегә вакытында дөрес ярдәм күрсәтү бик мөһим. Ләкин барыннан да яхшысы — агулануны булдырмау.

ХӘМЕР КҮЗНЕҢ НУРЫН АЛА

Эчкечене бер күрүдә танысың — аның күзеннән нур качкан була. Ялан-ялан шулай эчеп, күзен нурсызландырып йөрүне гадәт итеп алса, аның начар күрә башлавы, күзләренең тәмам бозылуы бик ихтимал. Кеше бер заман бер сәер нәрсә сизә башлый: ул эңгер-меңгер чакта көндезгегә караганда әйбәтрәк күрә шикелле. Ләкин бу шулай тоела гына, асылда аның күзләре гомумән начарлана бара, врач моны бик тиз ачыклый. Кайбер эчкечеләрдә уңай скотома дигән чир дә башлана. Аны гади генә бер чара белән белеп була: бер күзне каплап, икенчесе белән нык яктыртылган ак кәгазь битенә карыйсың, аннары бераз гына күз алдына учны куеп торасың. Учны алгач, каршыдагы ак кәгазь битенә озынча формадагы сары, күксел яки кара тап төшкән сыман тоела. Берничә секундтан соң ул тап юкка чыга. Андый кешенең күз төбен җентекләп караган врач күрү нервысының аксылланып киткәнен ачыклый. Димәк, кайбер нерв җепселләре һәлак булган, дигән сүз.

Башлангыч чорында бу чирне дәвалап, күзне саклап була әле. Моның өчен иң беренче чиратта эчүне ташларга, авызга бер грамм да хәмер капмаска кирәк. Югыйсә дөнья яктысын күрүдән мәхрүм булуыгыз бар.

Алкоголь гомумән күзгә бик нык тәэсир итә.

Кайвакыт мондый хәлләр дә була: ана яңа туган баласының күзе зәгыйфь икәнлеген белә. Сөенеч көтеп торганда нинди зур хәсрәт! Андый чакта кешегә ярдәм итү дә бик кыен бит, күзнең тумыштан булган зәгыйфьлеген дәвалау бик авыр, ә кайчакта мөмкин дә түгел. Чөнки ул зәгыйфьлек күрү нервысының, күз алмасының яки бәбәгенең дөрес формалашмавыннан килә.

Каян килә бу бәхетсезлек! Эзли-тикшеренә башласаң, бер нәрсә ачыклана: баланы гарип иткән нәрсә — ана йөкле чакта эчкән хәмер икән.

Табигать ана карынында яткан яралгыга зарарлы матдәләр үтеп кермәсен өчен киртәләр куйган. Ләкин кайбер агуларны, шул исәптән алкогольне ул киртәләр генә тоткарламый, алар кан агышы белән яралгыга тиз арада барып җитәләр һәм аның үсешенә бик зур тискәре йогынты ясыйлар.

Аракы, шараблар йөклелекнең беренче атналарында аеруча зыянлы. Баланың күзе бик иртә формалаша башлый. Өченче атнада яралгының буе өч миллиметр гына чакта, баш мие белән тоташып, күз куыклары барлыкка килә. Алтынчы атнада күз тукымалары, бәбәк ярала. Баланың баш мие зур тизлек белән үсә. Кан агымы белән баш миенә үтеп кергән алкоголь баланың нерв күзәнәкләрен бик нык агулый. Сирәк очракта күз алмасы урынына ниндидер төерләр урнашкан балалар туа. Сораштыра башласаң, аларның аналары йөкле чакта бик еш һәм күпләп аракы эчкән булып чыга.

Хайваннар белән үткәрелгән тәҗрибәләр дә алкогольнең бала яралгысына, бигрәк тә аның күзләренә зур зыян китерүе хакында сөйлиләр. Хайваннарның азыгына аракы шәраб кушсаң, аларның балалары зәгыйфь һәм еш кына начар күрә торган була. Диңгез суына әз генә хәмер кушсаң да, анда йөзгән маймычларның кайберләре бер генә күзле булып үсәләр.

Йөкле хатыннар боларны яхшы белергә тиешләр. Кунак чакырганда да, бәйрәмнәрдә бокал күтәргәнче бик нык уйланыгыз: соңыннан үкенерлек булмасмы!

чөнки аның баллылыгы кимрәк. Шикәр чире белән авыручыларга ризыктагы углеводлар микъдарын бик төгәл исәпләп торырга туры килә, шунлыктан без дә тәкъдим ителгән ашлардагы углеводлар микъдарын күрсәтәбез.

К о м п о т. Киптерелгән җимешләрне юалар, өстенә кайнап торган су салалар, 10—15 минут кайнаталар. Әзер компотка ксилит салып болгаталар, суыталар.

1 стаканга: 10 г кара җимеш, 10 г кипкән алма һәм груша, 15 г ксилит яки 30 г сорбит, 150 г су кирәк. Анда 19 г углевод була.

С ө т л е ж е л е. Сөтне кайнатып, ксилит һәм суда җебетелгән желатин салалар. Болгаталар, кайнатып чыгаралар, формаларга салып суыталар.

1 кешегә: 120 г сөт, 15 г ксилит, 3 г желатин алына, анда 5,4 г углевод була.

А л м а к ү б е г е. Алманы әрчеп, кыргычта уалар, 5 г ксилит кушып, салкынча урынга куялар. Кабыкларын, үзәген бер савытка салып, өстенә кайнап торган су коялар, 10 г ксилит өстиләр дә кайнарга куялар. 5—10 минут кайнагач, алып сөзәләр. Аңа суда җебетелгән желатин салалар, болгата торып, кайнатып чыгаралар, бераз суыталар һәм салкын урында күбекләнгәнче болгаталар. Болгатканда уылган алманы әкренләп өстиләр. Бөтенесен яхшылап болгаткач, формага салып суыталар.

Бер кешегә: 40 г әрчелгән алма, 15 г ксилит, 3 г желатин, 100 г су алына. Анда 4,5 г углевод була.

А л м а с у м с а с ы. Алманы әрчеп турыйлар, ксилит өстәп, әз генә су кушып, ныгытып болгаталар, суыталар.

Камырны түбәндәгечә әзерлиләр: җылы сөткә чүпрәне изеп, тоз, он кушып басалар, аннары эрегән май салып, тагын басалар. Камырны 2—3 сәгатькә ачырга куялар.

Әзер камырны онлы кунага салып, бүләләр, җәяләр, эченә әзер алманы салып, сумсалар ясыйлар, 15—20 минут җылы урында тоткач, духовкада яки мичтә 30—40 минут пешереп алалар.

1 кешегә: 40 г он, 60 г алма, йомырканың дүрттән бере, 20 г сөт, 10 г ак май, 4 г чүпрә, 10 г ксилит, 2 г тоз алына. Анда 36 г углевод була.

ларны бик бизи. Ләкин алар да игътибар сорый, аларны әледән-әле чистартырга, тәртипкә китерергә кирәк.

Алтыннан ясалган алка, йөзек, беләзек, брошкаларны сабынлы суга салып бераз тоткач, йомшак теш щеткасы белән чистарталар. Каптырмаларны аеруча җентекләп тазартырга туры килә. Алтын чылбырны шешәгә, сабынлы суга салып, чистарганчы шешәне селкиләр.

Йөзек кашларының асты аеруча керләнүчән була. Аны одеколонга яки гөлсирингә манчылган мамык уралган шырпы белән чистарту җайлы. Соңыннан йөзекне фланель яисә замша кисәге белән ышкып ялтыраталар. Йөзекләрне очлы әйбер белән чистартырга ярамый, чөнки алтынның тырналуы мөмкин. Йөзекләр матурлыгын сакласын дисәгез, кул юганда аларны сала торган булыгыз.

* * *

Көмештән ясалган яисә көмеш йөгертелгән бизәү әйберләрен башта сабынлы суда юып, аннары сукно кисәге белән ялтыраталар. Каралып киткән әйберләрне чәй содасы белән ышкырга яки теш порошогы белән чистартырга була.

* * *

Пыяла төймәләрне, брошкаларны кер юу порошогы салынган суда юып чиста суда чайкыйлар һәм чиста, йомшак сөлге белән корыталар. Эре төймәләрне щетка белән ышкып та юарга була, әмма ясалма энҗене щетка белән юарга ярамый. Җепкә яки резинкага тезелгән төймәләрне сабынсыз су белән генә юарга кирәк, югыйсә җеп өзелә.

* * *

Пластмассадан ясалган бизәнү әйберләрен сабынсыз, порошоксыз су белән генә юалар. Юар алдыннан төймәләрнең җебен алалар, юып киптергәч, яңадан тезәләр.

* * *

Гәрәбәне һәм фил сөягеннән ясалган әйберләрне сабынлы җылы суда юарга була. Әгәр фил сөяге тапланган яки саргайган булса, аны ун минутка әз генә хлорлы известь салынган суда тоталар, аннары йомшак чүпрәк белән сак кына сөртәләр.

* * *

Бакыр әйберләрне акбур кушылган нашатыр спирты белән чистарту әйбәт. Кайчакта коры мамык белән ышкып ялтырату да җитә. Бакыр да, көмеш тә вакыт узу белән тутыгалар. Тутык киемгә йокмасын өчен, ул әйберләрне аскы яктан тырнак лагы белән буяп куярга була. Болай эшләгәч, алар артык нык тутыкмыйлар да.

Баш редактор —
В. Ф. Ихсанова.

Редколлегия членнары:

Н. З. Закирова
Ә. Ш. Мусина
Л. М. Мәһдиева
И. Г. Сункишева
С. Г. Сөләйманова
К. Г. Шәмсетдинова
І. Ш. Шәрәфетдинов
(баш редактор урынбасары)
И. Г. Юзеев
З. Н. Якубова
Р. А. Җиһаншина

Художник
Х. Әхмәтҗанов.

Техник редактор
Э. Әдиатуллина.

Общественно-политический
и литературно-
художественный журнал
«Азат хатын»
(«ОСВОБОЖДЕННАЯ
ЖЕНЩИНА»)
на татарском языке.

Производствога бирелде
10/II-1978 ел.
Басарга кул куелды
21/III-1978 ел.
Тираж 364000.
Заказ В-35.
ПФ 07034.
Кәгазь форматы 60×90 1/8.
Күләме 3 басма табак.

КПССның
Татарстан
өлкә комитеты
нәшрияты
типографиясе.
Казан,
Декабристлар урамы, 2.

ТЕЛЕФОННАР:

хатлар һәм авыл хуҗалыгы
бүлекләре — 3-07-46;
промышленность, пропаганда,
әдәбият һәм сәнгать
бүлекләре — 3-07-42;
художник — 3-07-44;
фотокорреспондент —
3-07-67;
җаваплы секретарь —
3-57-69;
кабул итү бүлмәсе —
3-07-40;
баш редактор —
3-38-75.

БЕЗНЕҢ АДРЕС:

г. Казань — 420066,
ул.
Декабристов, 2,
редакция журнала
«АЗАТ ХАТЫН».



Р. Якупов фотосы.

Рәссам яшьлеге

Әхсән Фәтхетдинов рәсемнәренә карасаң, җанны рәхәт моңсулык биләп ала. Тагын да җентекләбрәк күзәтсәң, әсәрләрне иҗат итүдә рәссамның бик нык тырышуын, тир түгүен аңлыйсың. Бу рәсемнәр кеше күңелен әсир итәрлек дәрәҗәгә җиткәнче авторның күпме газаплануын тоясың.

Иҗат газабына әзер тору өчен, язмышын сәнгатькә бәйләгән кешеләрнең тормышта да кыенлыклар күрүе хәерлерәк бугай... Әхсән турында сөйләгәндә, аның таланты кечкенәдән үк мәгълүм булган, дип әйтүе кыен. Ул математика белән «җенләнгән». Үзе педучилищены тәмамлаган. Армия сафларындагы хезмәттән соң Нижний Тагил педагогия институтының сәнгатьчә графика бүлегенә керү өчен гариза язган.

Беренче курста Әхсәннән көчлерәк студентлар күп кебек тоелган. Икенче курста инде аның исеме сәләтле студентлар рәтеннән телгә алына башлаган. Өченче курста исә егет башкалардан аерылып торган. Дүртенче курста аңа... институтта укытырга тәкъдим ясаганнар. Ул өч ел буе яшь талантларга дәрес биргән.

Әхсән ясалачак рәсемнәренә тема эзләп озак баш ватмый. Аның әллә кайчан сайлап алган һәм бүгенгәчә шуңа тугры калган темасы бар, бу — Ватан тормышы, туган ил кешеләре. Туган илнең тарихы, фольклоры, аның нечкә күңелле, баһадир йөрәкле кешеләре рәссам әсәрләренең нигезен тәшкил итә. Образлар, күп очракта, табигать күренешләре белән аерылгысыз бәйләнештә биреләләр. Киң болыннар, яшел хәтфә ябынган тау битләре, бер яктан, туган җирнең хөрлеген, матурлыгын тасвирласа, икенче яктан, рәссам мөрәҗәгать иткән образларның эчке халәтен ачып бирүгә хезмәт итә.

Әхсән иҗатында туган образларга халыкчанлык, бигрәк тә татар милли рухын чагылдыру сыйфатлары хас.

Рәссамның осталыгы, иҗат үзенчәлекләре турында сүз куерса, әлегә стиленең ышанычлы эзгә төшеп җитмәвен, рәсем ясау техникасы буенча аңа әле шактый тырышырга кирәклеген искәрергә мөмкин. Аңа тиздән кырык яшь тулачак. Рәсем ясау техникасын үзләштерергә соңрак түгелме соң! Гадәттә мондый нәрсәләр белән егерме яшькә кадәр шөгыльләнәләр!!

Һәр көнен баштанаяк хезмәткә, эзләнүләргә багышлаучан рәссам болай туп-туры бирелгән сорауга да аптырап калмый.


— Алай булгач, миңа әле егерме тулмагандыр..., — дип елмая.

Чыннан да, аның тырышлыгы егерме яшьлек егетләрнеке кебек, хезмәткә карашы, сәнгатькә булган таләпләре исә җитлеккән, ир уртасы кешесенекенә охшаш. Кайчак аның әлегәчә зур-зур күргәзмәләрдә катнаша алмавына, әсәрләренә карата төпле киңәшләр ишетмәвенә, осталыкны үстерергә мөмкинлекләр җитенкерәмәвенә ачуы чыга. Әмма киләчәккә булган өмет, яктыга ышаныч мондый күңелсезлекләрне җиңә, армыйталмый иҗат итәргә рухландыра.


Килер бер көн, сез, кадерле укучылар, бүген бу журнал битендә тәкъдим ителгән рәсемнәрнең авторы Әхсән Фәтхетдиновның зур күргәзмәсе турында ишетерсез. Бүген исә ул республикабызның Түбән Кама шәһәрен бизәүче тырыш рәссамнар сафында иҗат итә.

Вахит ШӘРИПОВ.

Әхсән Фәтхетдинов рәсемнәре.








«Алтын туй».

«Сагыш».

«Тукай шигырьләре».



ТЫШЛЫКЛАР



Беренче биттә: Түбән Кама шәһәрендәге 44 нче техник училищеның тиздән нефть-химия производствосына аппаратчы булып эшкә китәчәк уку алдынгысы Зоя Федосеева.

Икенче биттә: Казанның Ирек мәйданындагы Ленин һәйкәле.

Рифкат ЯКУПОВ фотолары.

Бәясе 20 тиен
Индекс 73002



ЧЫГАРЫЛЫШ КИЧӘЛӘРЕ ӨЧЕН



Модалар